وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# Дин вә Мәгыйшәт

№2 (99). 26-08-2011 / Рамазан – 1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Ата-ананы ярату – аларның телен дә ярату ▷3◁




Татарга йөз тоткан ислам ▷6◁



Казанда милли киемнәрнең халыкара конкурсы үтә ▷7◁

# Бисмилләхир-рахманиррахим! Мөхтәрәм дин кардәшләребез!



**Чын күңелдән барыгызны да якынлашып килүче Ураза гаете белән котлыйм!**

**Ураза гаете - дөньяның төрле почмакларында яшәүче миллионлаган мөселманнар өчен иң бөек һәм әһәмиятле бәйрәмнәрнең берсе. Күпләребез өчен Рамазан ае гыйбадәт кылу, мәңгелек турында җитди уйлану, үз асылыбызга кайту, ягъни рухи чистарыну ае булды. Әлеге изге айда ислам диненең яңа яклары белән таныштык, төннәр буе йокламыйча гыйбадәт кылуыбыз белән Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгаләгә тагын да якыная алдык. Бу ай күңелләребезне иман нуры белән бизәде. Аллаһы Тәгалә каршындагы изге бурычыбызны үтәп, рухи канәгатьлелеккә ирешә алдык.**

**Әлеге айның бөтен хикмәте дә шунда - Рамазан ахырында үзебезне яңа туган сабыйдай хис итәбез, рух һәм тән сәламәтлегенә ирешәбез. Ураза бәйрәме, шатлык символы кебек булганга, без аны һәр ел күтәренке кәеф, сөенеч белән каршы алабыз. Бу елда да Аллаһы Тәгаләгә рухи ныклыгыбызны күрсәтә алдык, шуңа да шөкер кылыйк. Хәзер без үзебезнең көчебезгә генә түгел, мөселман өммәтенең ни дәрәҗәдә көчле, нык икәнлегенә дә инандык.**

**Әлеге бәйрәм көне эчкерсез елмаюларыгыз, игелекле гамәлләрегез белән тулсын. Рамазан аенда күрсәткән сабырлык, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек кебек сыйфатларыбыз башка айларда да дәвам итсә иде. Аллаһы Тәгалә безгә көч-куәт биреп, халкыбызга, динебезгә, ватаныбызга хезмәт итәргә язса иде.**

**Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә тоткан уразаларыгызны, кылган гамәлгыйбадәтләребезне кабул итсен, үзенең рәхим-шәфкатеннән ташламасын. Нәфесебездән өстен булып, акылыбыз кушканча яхшы гамәлләр генә кылып, киләчәк Рамазан аен да исәнлек-саулыкта каршы алырга насыйп итсә иде! Әмин!**

**Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## И Рамазан

Үтеп кердең дә син йөрәкләргә,
Китеп барасың да түгелме?
Юк җиһанда синдәй оста табиб,
Пакьләндергән тәнне, күңелне.

И Рамазан! Синдәй мөгаллимгә
Юлыкмадым һичбер мәктәптә.
Сиңа керсә, хәтта наркоман да
Күнә икән әхлак-әдәпкә.

Үрнәк алып, синең ысуллардан
Файдаланса башка мәктәпләр,
Булыр иде балаларда тәүфыйк,
Кимер иде хәвеф-хәтәрләр.

И Рамазан! Китсәң дә син Җирдән,
Күңелләрдән һич тә китмәссең.
Нурың яктысында каршылыйбыз
Гает көннәребез иртәсен.

Синдә сафландырган калебләрне
Сафландырсак иде хаҗда да.
Хушлашабыз, кавышуны сорап,
Өметебез, фәкать, Раббыда.

Бәйрәмнәребез булсын мөбарәк,
Килер көннәребез хәерле.
Кабул кылып безнең уразаны,
Итсә иде Аллаһ җәннәтле.

**Рәисә ФӘЙЗУЛЛИНА.**
**Түбән Кама районы**

# Кадер кичәсе - олуг нигъмәт ул

**Без, Әлһәмдүлилләһ, Рамазан-шәриф аен тәгәлләп киләбез. Бу айның соңгы ун көне иң кадерле көннәр һәм иң мөбарәк төннәрдән хисаплана. Һәрберебез дә шуның кадерен белеп, тиешле рәвештә үткәрергә Аллаһ Раббым насыйп әйләсә иде.**

Кем белә, без киләсе Рамазанны әллә күрә алабыз, әллә юк. Шуңа күрә бүгенге Рамазанның форсатын бушка үткәрә күрмәгез. Бигрәк тә менә хәзер, Кадер кичәсе якынайган көннәрдә. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә бу төн турында Коръәни-Кәримдә "Кадер" дигән бер сүрә иңдергән. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Иннәә әңзәлнәһү фи ләйләтил Кадр". ("Чынлыкта, без (Коръәнне) Кадер кичәсендә иңдердек"). Ягъни Рәсүлебезгә (с.г.в.) нәкъ кырык яшь тулгач, Нур тавында Рамазанның 27 нче кичендә, Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримнең беренче биш аятен Рәсүлебезгә (с.г.в.) иңдереп, ул (с.г.в.) бу кичәдә Пәйгамбәр булды. Шуннан соң дәвам итеп, Аллаһы Тәгалә әйтә: "Вә мә әдракә мә ләйләтүль Кадр". ("Беләсеңме, нинди кичә соң ул Кадер кичәсе?") "Ләйләтүл Кадери хайрум мин әлфи шәһр". ("Ул, Кадер кичәсе, мең айдан да хәерлерәк"). Әгәр дә төптән уйлап карасак, мең дигән "әлф" сүзе - хәзерге һәм исламга кадәр булган гарәп телендә дә төгәл меңне аңлатмый. Аның төп мәгънәсе күплек санын белдерү. (Мисал өчен, мөселман дөньясындагы "Мең дә бер кичә" әкиятен китерергә мөмкин, аны да гел, буыннан-буынга, чиксез сөйләп була.) Мең ай - 83 ел да дүрт айга туры килә. Әмма ләкин Кадер кичәсе, 83 ел гына да түгел, меңәрләгән еллар гына да түгел, хисапсыз дәрәҗәдә кадерде. Коръәни-Кәрим иңгән кичә бу! Гайсә пәйгамбәрдән соң 600 ел үткәч, Аллаһы Тәгалә тагын бер китабын - Коръәнне җибәрә. Шушы 600 елда кешеләр адашып, саташып, гөнаһларга батып беткәннәр.




Алар үзләренең кешелеклелек дәрәҗәсен югалта төшкәннәр иде. Шуннан соң караңгылыктан нурга алып чыгучы, адәм балаларының әшәкелекләреннән, әдәпсезлекләреннән әхлаклылыкка, кешелеклелек дәрәҗәсенә күтәрүче Коръән китабы инде. Коръәни-Кәримдә килгән аятьләрнең хикмәтен мең елдан соң гына ача башладылар. Кечкенә генә мисал. XVII гасырга кадәр галимнәр, фәлсәфәчеләр, шул ук Аристотель, Птолемей, Франслар Кояш та, Җир дә йөрми, бер урында тора дип әйттеләр. Бу XVII гасыр башында гына билгеле булды. Ә Коръәни-Кәрим VII гасырда ук: "Кояш үзенең юлы белән бер вакытына кадәр йөри, шул вакыты узгач, Кояш сүнә. Кояш кына түгел, Җир дә, башка планеталар да үзләренең юлларында орбита булып йөзәләр", - ди. (Бу Кадер кичәсендә иңгән китапта шулай.) Мең ай гына да түгел, мең ел узгач ачтылар моны галимнәр. Инде Коръәни-Кәримдә әйтелгән космос белән генә дә түгел, кешелек дөньясы, гаиләдәге ир белән хатын арасында булган мөнәсәбәт, балалар белән ата-ана арасында булган мөнәсәбәт, җәмгыятьтәге булган икътисад, сәясәт, дәвалану чаралары, әдәп-әхлак нормалары турында сөйләсәк, сүзләр һичкайчан бетәчәк түгел. Имамнар, галимнәр мең еллардан бирле вәгазьләр сөйлиләр һәм барыбер Коръәннең хикмәтен ачып бетерә алмыйлар. Ләкин адәм балалары, барыбер, күп вакытта Кадер кичәсенең кадерен аңламыйлар.

Әмма шуны әйтәсем килә: кайбер риваятьләрдә бар ки, Сөләйман пәйгамбәр Җир йөзендә 500 ай хөкем иткән (ягъни, 41 ел), Зөлкарнәйн (ул мәгъриб белән мәшрикъка сәяхәт иткән кеше) 500 ай хөкем иткән; Сөләйман белән Зөлкарнәйннең патшалыгы - 91 ай.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# Кадер кичәсе - олуг нигъмәт ул

(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)

Бер кичтә иман белән, дога белән, истигъфар белән үткәргән бер мескен яисә әби-бабайлар Аллаһы Тәгалә Сөләйман белән Зөлкарнәйннең патшалыгы вакыты әҗер-савабын да бирә. Сөләйман (г.в.) никадәр идарә иткән, нихәтле изгелек кылган. Аллаһы Тәгалә бер кичтә шуларның савабы кадәр безгә савап бирә ала. Сөләйман (г.в.) вакытында да яңгыр яумаган. Яңгыр яумагач Сөләйман (г.в.) үзенең кавеме белән: "Әйдәгез, чыгыйк, истиска намазы укыйк", - дип халыкны алып чыккан. Кырга чыксалар, Сөләйман (г.в.) белән бергә утырып, кырмыска да, кулларын өскә күтәреп, дога кыла икән: "Йа, Раббым, без дә синең колларың. Безгә бик авыр, безгә бер тамчы суыңны гына иңдер инде", - дип, кырмыска аның артына ятып, әйткән: "Кайтабыз. Сезнең өчен дога кылдылар инде". Хәтта кошлар да, хайваннар да дога кыла. Мөхәммәд (с.г.в.) бер хәдисшәрифендә: "Адәм балаларының гөнаһлары шуның кадәр күбәйгән, әгәр дә бөҗәкләр, кошлар һәм изге юлда йөргән картлар булмаса, Аллаһы Тәгалә бер тамчы да яңгыр яудырмас иде", - ди. Бу кичәне дөрес үткәрсәк, Сөләйман белән Зөлкарнәйннең - икесенең патшалыгыннан да хәерлерәк әҗер алачакбыз. Әмма ләкин белегез: шайтан бу төндә адәм балаларына һәм мөселманнарга бер зыян китерә алмый торган булачак. Бәни Исраил кавемендә дүрт кеше - Әюб пәйгамбәр, Зәкәрия, Яхъя һәм тагын бер изге зат - дүрт кеше барысы бергә сиксәнешәр ел бер гөнаһ кылмыйча яшәгәннәр. Кыямәт көне кавеменең мондый гыйбадәтләрне кылырга, мондый изгелеккә ирешергә безнең вакытыбыз җитәрме дип сораганда, Аллаһы Тәгалә шушы сүрәне иңдерде. Әгәр дә шушы кичәдә чын ихлас күңел, ният белән, Аллаһыга ялварып-сорап, кичәбезне үткәрсәк, Әюб, Зәкәрия, Яхъя пәйгамбәрләрнең изгелегеннән дә арттырып алачакбыз. Бу акылга сыя алмый торган әйбер түгел. Моны аңлатып булмый.

Шуңа күрә шушы кичәдә безнең язмышларыбыз да карала. "Кадер" - "тәкъдир" дигән сүз. Бу төндә безнең язмышларыбызны Аллаһы Тәгалә карый һәм әмер кыла: безнең гомеребезне я озынайта, я кыскарта, ризыгыбызны яки киңәйтә, яки тарайта. Адәм баласының калебенә, аның догасына караячак ул. Шуңа күрә бу кичәдә Аллаһның олуг рәхмәтенә ия булырга мөмкин. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә әйтә: "Тәнәззәлүл мәләикәтү вәр-руху фиихә биизни". ("Бу кичтә фәрештәләр җиргә төшә"). Хәтта Җәбраил, Микаил, Исрафил фәрештәләре җир йөзенә төшә. "Раббиһим миң күлли әмр". ("Алар Аллаһы Тәгаләнең рөхсәте белән җиргә төшәләр"). Риваятьләрдә әйтелә, фәрештәләр җир йөзенә шулкадәр күп төшәрләр, берсе-берсенә урын табу аларга авыр булыр. Бөтен җир йөзе тулыр. Аларның максатлары нинди? "Сәләмүн һия хәттә мәтләгильфәҗрь". ("Иртәнге таңга кадәр сәламне таратып (ягъни тынычлыкны таратып)").

Һәрбер мөселман янына килеп, фәрештәләр әйтә: "Сиңа Аллаһның сәламе булсын". Әгәр дә сез дога кылып утырасыз икән, сез дога кылган саен, Җир йөзендәге фәрештәләр - Җәбраил, Микаил, Исрафилләр сезнең догага "Әмин" дип торачаклар. Бер минут кыласың икән, бер минут кылалар синең белән. Аннан соң икенче тарафка китәләр. Ике минут кылсаң, ике минутка киләләр. Таң атканчыга кадәр Җир йөзендәге бөтен мөселманнарның догасына барча фәрештәләр "Әмин" дип тора. Мондый мәҗлес дөньяда юк. Нәрсә сорасаң, "Әмин" дип, сиңа Аллаһның сәламе булсын, Аллаһы Тәгалә сине гафу итсен дип, бөтен фәрештәләр мөселман кешесенә әйтәләр: "Бу мөселман кешесен гафу ит, я Раббым, моны рәхимлегең астына ал". Әмма ләкин адәм баласының бер кимчелеге бар - ул нәфес. Менә бу кичәдә безнең нәфесебез иң зур дошманыбыз булачак.

"Сәләмүн һия" дигән сүзнең тәрҗемәсе - мөселман кешесенә бер шайтан да вәсвәсә кыла алмаячак. Белегез: Кадер кичәсендә, сез, шайтан булмау сәбәпле, үзегезгә үзегез анализ ясаячаксыз. Бу кичәдә башыгызга нинди генә бозык фикерләр керсә дә, ул сезнең фикерегез. Бу сезнең кимчелегегез. Шайтанның Кадер кичәсендә катнашы юк. Әгәр дә син: "Доганы озак кыла алмыйм, "Мин лучше футбол карыйм", - дип әйтәсең яисә ятып йоклыйсың икән, димәк, син үзең шундый. Дингә булган мөнәсәбәтегезне Кадер кичәсендә беләчәксез. Һәм икенче көнне иртә белән торгач, үзегезгә үзегез анализ ясагыз - дингә карашыгыз нинди? Үзегезнең нинди мөселман икәнлегегезне шуннан беләсез.

Шуңа күрә Кадер кичәсендә Аллаһы Тәгалә тәкъдирне билгели. Сезнең нинди икәнлегегез, йөзегез ачыктан-ачык күренә. Менә шушы төндә, җәмәгать, Аллаһы Тәгалә адәм баласының бөтен гөнаһларын кичерә. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ихлас күңелдән тәүбә кылып, иманын яңарткан кеше, шуннан соң изге гамәлләрен арттырган кешеләрнең шушы Кадер кичәсенә кадәр кылган гөнаһлары сөртелми". Ә нишли? Изге гамәлгә әйләндерелә. Бөтен гөнаһ изге булып языла. Бу Кадер кичәсендә мөселманнарга Аллаһы Тәгаләнең бүләге була. Әгәр дә ихлас күңелдән тәүбә итеп, үзебезнең тормышыбызны хәерле юлда үткәрергә дигән максат куйсак, Ул эшләнгән гөнаһларыбызны изгелекләр дип билгеләр. Һәм дә, җәмәгать, безнең тагын бер кимчелегебез бар, Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә: "Кемнәр минем Раббым - Аллаһ дип әйтә икән, әйткән сүзләрен үтәсен". Ягъни, инану белән бергә, гыйбадәт тә кирәк. Менә шуннан фәрештәләр бу кешегә төшә.

Чын мөселман кешесе Аллаһының рәхмәтенә ирешергә теләсә, сүз белән генә түгел, хәтта төнлә торып, Кадер кичәсендә дога кылып, икенче көнне үк Аллаһның кушуын үтәми торган юлга күчә икән, Кадер кичәсенең әһәмияте калмаячак. Без Кадер кичәсеннән соң бер башка күтәрелергә тиеш. Шунда без киләсе Рамазанга кадәр җитәрлек көч алырга тиешбез. Менә бу безнең тормыш рәвеше. Дөнья белән генә түгел, ахирәткә дә ышану - олуг бер нигъмәт. Аллаһы Тәгалә Рамазан ае дәвамында тоткан уразаларыбызны, кичләрен укыган намазларыбызны, тапшырганбиргән хәер-сәдакаларыбызны кабул кылсын!

**Солтан хәзрәт МУРАДИМОВ,**
**Казанның "Рамазан" мәчете имам-хатыйбы**

## Мөселман киносы фестивале старт ала

**Казанда җиденче тапкыр уздырылучы Халыкара мөселман киносы фестивале ачылуга санаулы көннәр генә калып бара. Фестивальдә катнашырга теләүче хезмәтләр саны күбрәк булса да, быелгы кинофорум фестивале программасына 28 илдән 83 фильм сайлап алынган.**

Конкурстан тыш программада барлыгы 35 фильм тәкъдим ителәчәк, ди чараны оештыручылар. Алар арасында нәфис, документаль, анимацион фильмнар бар. Фестивальнең махсус программасы кысаларында "Үзбәкстанда эшләнгән" һәм "Татарстанда эшләнгән" дигән исем астында тамашачыны моңарчы аз таныш булган милли кинематограф мәктәбе эшчәнлеге белән таныштыру да каралган.

Исегезгә төшерәбез, 6-11 сентябрь көннәрендә башкалабыз Казан мөселман киносы сәнгате үзәгенә әвереләчәк. Казанга Мәскәүдән, чит илләрдән кино йолдызларның килү көтелә.

Шунысы да куанычлы, фестивальдә күрсәтеләчәк фильмнарны Казан халкы һәм Казан кунаклары бушлай тамаша кыла алачак. Быелгы фестиваль фильмнары Grand Cinema кинотеатрында тәкъдим ителә.

**intertat.ru сайтыннан алынды**



# Бәйрәм көнне генә сабый булып торыйм

*...Таң алдыннан яңлыш йоклап киткән чагым,*
*Төшемдә дә нурлы бәйрәм көткән чагым;*
*Әнкәемнең тавышлары колагымда:*
*"Гает җитте, тор аппагым! Тор, аппагым!"*

**Г. ТУКАЙ**




Бәйрәмнәр күп булды безнең балачакта: ямьле җәйләр белән бергә килгән Сабантуйлар кышларны бизәгән Яңа еллар, язларны назлаган Әниләр бәйрәмнәре ел саен кабатлана торган туган көннәр, дисеңме... Ә күңел ул бәйрәмнәрнең барысын да түгел, балалык сиземләве белән тойган зур серне яшергән Ураза, Корбан бәйрәмнәрен өзелеп сагына. Әби-бабаларымның сәхәргә торган вакытларында үземнең дә уяныргә тырышуларым, бабамның соң гына тәравих намазыннан кайтулары, гает көннәрендә әтиәниемнең яңа киемнәр кигезеп куандырулары, хуш исле бәйрәм коймаклары бүген дә балачагыма дәшә. Нәкъ сөекле шагыйребез Габдулла Тукай әйткәнчә:

***...Бәйрәм көнне генә***
***сабый булып торыйм,***
***Рәхәтләнеп сикереп,***
***көлеп, уйнап йөрим.***

("Бәйрәм вә сабыйлык вакыты").

Аллаһ рәхмәте белән ул вакыттагы сер төене инде күптән чишелде. Без, мөэминмөселманнар, бүген намазларыбызны кайчандыр авыл-шәһәрләрне нурсыз калдырып, манаралары киселгән мәчетләр урыннарында якты нур булып калыккан яңа мәчетләрдә укыйбыз, әлхәмдүлилләһ; гает, җомга көннәрендә мәчетләр халык белән тула, дини гыйлем алырга теләүчеләргә дә ирек - һичнинди чикләүләр юк. Рамазан ае керү белән мәчетләрдә көн дә үткәрелә торган ифтар мәҗлесләренә җыелган халыкны күреп, күзләргә яшьләр килә. Уйларым кабат, көчле тыюларга карамастан, Хак Тәгаләбезгә тугрылыклы булып калып, динебезне безгә - оныкларына мирас итеп тапшыра алган әби-бабаларыма кайта, аларның тәкъвалыкларына сокланам, рәхмәт укыйм.

Озын-озын көннәрдә, Рамазан ае уразаларын тотып, калебемне сафландыра алуым белән мин үземне аларга бурычлы саныйм. Балаларымның Аллаһы Тәгаләдән читләшергә мәҗбүр ителүләре белән, һичшиксез, килешмәгән алар. Бу кимсетүләргә сабыр итүдән башка чаралары калмаса да, уразалы хәлләрендә күз яшьләре аша кылган догалары кабул булган. Раббыбыз, аларның эчкерсез догалары сәбәпле, безне динебезгә кайтаргандыр да, әлхәмдүлилләһ.

Хәзер үзебез, әби-бабаларыбыз үрнәгендә, көннәрнең озын һәм кызу булуына карамастан, Хак Тәгаләгә шөкер итә-итә, уразаларыбызны тотып, Аллаһ каршындагы фарыз бурычларыбызны өстебездән төшерергә омтылып яшибез. Ашау-эчүләребездән тыелып тору нәтиҗәсендә, бер йотым суның, бер бөртек икмәк валчыгының Раббыбыз тарафыннан бирелгән нинди зур нигъмәт икәнен кабат искә төшереп кенә калмыйча, ризыкны исраф итүдән саклануның әһәмиятен балаларыбызга да төшендерергә тырышабыз.

Уразаларыбыз барышында, көннәрнең артык кызулыгы сәбәпле, хәлебез киткәләгән чакларның булуы да иманнарыбызны ныгытты гына: сәламәтлекнең Аллаһ тарафыннан бирелгән чиксез зур байлык булуын, аны саклауның мөһимлеген тәннәребез аша гына түгел, аңнарыбыз аша да тойдык.

*(Ахыры 7 нче биттә.)*

# Ата-ананы ярату – аларның телен дә ярату

Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтте:

أعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ: ( وإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلآئِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الأرْضِ خَلِيفَةً قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَنْ يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَآءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لاَ تَعْلَمُونَ ) 30/2

"Һәм әйтте синең Раббың фәрештәләргә: "Мин, әлбәттә, җир өстендә хәлифә итеп Адәмне кылмакчымын. Фәрештәләр әйттеләр: "Ий, Раббыбыз! Бозыклык кылучы, сугышып кан түгүче затны җир өстенә хәлифә кыласыңмы? Без исә Сине мактап тәсбихләр әйтәбез һәм Сине һәр кимчелектән пакьсең дип игътикад итәбез". Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә: "Дөреслектә, Мин сез белмәгәнне беләмен," - диде". ("Бакара (Сыер)" сүрәсе, 30 нчы аять).

"Бакара (Сыер)" сүрәсенең дәвамында Раббыбыз әйтә:

وَعَلَّمَ ءادَمَ الأَسْمَآءَ كُلَّهَا ثُمَّ عَرَضَهُمْ عَلَى الْمَلآئِكَةِ فَقَالَ أَنْبِئُونِي بِأَسْمَآءِ هَؤُلآءِ إِنْ كُنْتُمْ صَادِقِينَ ) 31/2

**2/31**

"Аллаһы Тәгалә Адәмгә исемнәрнең барчасын өйрәтте дә, фәрештәләргә әйтте: "Әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз, Адәм белгән исемнәрне барчасын әйтеп бирегез".("Бакара (Сыер)" сүрәсе, 31 нче аять).

Аятьләрдән күрүебезчә, җиргә хәлифә итеп куйганчы, Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламгә барча әйберләрнең, мәхлукларның, аларның җенесләренең исемнәрен өйрәтә. Ягъни барча сүзләрне. Һәм галимнәребез әйтте: монда барча сүзләр мәгънәсендә Адәм галәйһиссәламгә барча телләрнең өйрәтелүе әйтелә. Фәрештәләр Аллаһы Тәгаләгә: "Я, Раббыбыз, без Сиңа тәсбих кылабыз, Сине олылыйбыз. Син ни өчен җир йөзенә кан коючыны һәм бозыклык таратучыны хәлифә итеп куясың?" - дигәч, Аллаһ Тәгалә әйтте: "Бу әйберләрнең исемнәре хакында хәбәр бирегез, әгәр тугры булсагыз". Адәм галәйһиссәламнең фәрештәләрдән өстенлеге шушында күренде.

Моннан аңлашылганча, телләрне, барча әйберләрнең исемнәрен белү - ул гыйлем санала һәм гыйбадәткә караганда гыйлем өстенрәк. Аллаһы Тәгалә аяти Кәримәдә әйтте:

وَمِنْ ءَايَاتِهِ خَلْقُ السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضِ وَاخْتِلاَفُ أَلْسِنَتِكُمْ وَأَلْوَانِكُمْ إِنَّ فِي ذَلِكَ لآيَاتٍ لِلْعَالِمِينَ ) 22/30

**30/22**

"Аллаһы Тәгаләнең олуглыгының һәм кодрәтенең билгеләреннән - күкләрне һәм җирне яратуы, һәм телләрегезнең һәм үзегезнең төрле булуыгыз. Белүчеләр өчен бу әйберләрдә билгеләр бар", - диде. ("Рум" сүрәсе, 22 нче аять).

Ягъни Адәм балаларының төрле төстә, төрле телдә булуы - ул Аллаһы Тәгаләнең кодрәте һәм бөеклеге билгеләре. Әлбәттә, аңлаучылар өчен. Һәм бу телләрнең һәм төсләрнең аермалыгы Адәм балалары бер-берсен аерсыннар өчен. Бер атадан һәм анадан булуларына карамастан, Аллаһы Тәгалә аларны төрле-төрле итте. Бу әйберләр хикмәт өчен. Ягъни Аллаһы Тәгаләнең һәрбер эше хикмәтле. Кайберәүләр: "Ислам динендә тел һәм милләт юк", - диләр. Әмма Коръәни-Кәримдә тел дә бар, милләт тә бар. Аллаһы Тәгаләнең Китабында халыклар, аларның телләре һәм төсләре бер-берегезне тану өчен Бөек Затның билгеләре, дип әйтелгән. Моңа Раббыбыз нәрсә дип эндәште Адәм балаларына:

يَآ أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِن ذَكَرٍ وَأُنثَى وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوباً وَقَبَآئِلَ لِتَعَارَفُوا إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ) 13/49

"И кешеләр, Без сезне ир вә хатыннан яраттык, вә сездән халыклар вә кабиләләр кылдык бер-берегезне танып белер өчен. Дөреслектә, Аллаһ хозурында хөрмәтлерәгегез - тәкъвалырак булганыгыз. Дөреслектә, Аллаһ һәр нәрсәне белүче вә һәр эшегездән хәбәрдар". ("Хүҗүрат (Бүлмәләр) сүрәсе", 13 нче аять).

Аллаһы Тәгалә безне төрле халыклар, кабиләләр кылды, бер-беребезне тану, ярдәмләшү өчен. Ә бер-беребездән көлер яисә бер-беребезне кимсетер, мәсхәрә итәр, берсен икенчесеннән өстенрәк кылып, золым китерер өчен түгел. Аллаһы Тәгаләгә якынлыгыбыз нинди телдә сөйләшүебезгә бәйле түгел, ә бәлки тәкъвалыгыбызга бәйле. Тел - ул фәкать халыкларны аеручы билге, һәм ул бер милләтне, кавемне берләштерүче булып тора. Шуңа күрә дә кем нинди телдә сөйләшә, аңлаша - ул шул халыктан. Бу гыйбарәне кайбер гарәп галимнәре хәдис тә, риваять дип тә әйттеләр. Ягъни кем гарәпчә аңлашса - ул гарәп, диделәр. Шуңа нигезләнеп, кем урыс телендә генә аңлашса - ул урыс, татарча аңлашса - татар, башкортча аңлашса - башкорт дип әйтү дөрес була. Әлбәттә, үз милләтең теленә өстәп башка телләрне белү - ул зур мәртәбә. Коръәни-Кәрим һәм пәйгамбәребезнең (с.г.в.) сөннәте гарәп телендә булганга күрә, ахирәт бәхетенә ирешү өчен бу телне белү кирәк. Башка милләтләр белән аралашу, алар арасында динебезгә дәгъвәт кылу өчен аларның телләрен дә белү зарур. Әмма үз милләтең телен читкә этәрү, аны кыерсыту исәбенә түгел. Киресенчә, һәркем үз милләте телендә ачык, матур итеп сөйләшә белергә тиеш. Муса галәйһиссәлам Фиргавен янына барганда Аллаһы Тәгаләдән Һарунны үзе белән бергә җибәрүен үтенде. Чөнки Муса галәйһиссәлам сакаурак, ә Һарун бик ачык, матур итеп сөйләшә иде.



Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: "Кем нинди кавемгә, халыкка охшарга тырышса, ул алардан булыр", - дип әйтте. Башка милләтләргә охшарга тырышканнарның бу омтылышы сөйләшүләрендә генә түгел, ә йөзендә, киенүендә, үз-үзләрен тотышында да күренә. Татар, башкорт-мөселман мәктәпләре, балалар бакчалары була торып, үз балаңны башка чит телдә генә сөйләшергә өйрәтү, шул халыкның гореф гадәтләрендә тәрбияләү - бу, әлбәттә, инде монафыйклык билгесе һәм ул шулай ук мөселман кардәшләреңә, үз милләтеңә хыянәт тә булып тора.



Бервакыт пәйгамбәребез (с.г.в.) янына сахәбәләрдән булган бер егетне китерделәр һәм әйттеләр: "Йә, Рәсүлуллаһ, бу егет 7 сүрәне яттан белә". Пәйгамбәребез (с.г.в.) аңа бик гаҗәпләнде-сокланды һәм аннан соң болай диде: "Миңа яһүдләрдән язулар килә. Үзләренә дә язулар җибәрергә туры килә. Алар алдамасыннар өчен яһүд язуын өйрән". Шуннан соң теге егет яһүд язуын өйрәнде. Пәйгамбәребез (с.г.в.) сорады: "Син сырьян телен беләсеңме?" Ул гарәпләр белән византиялеләр арасында яшәүчеләрнең телләре иде. Егет: "Юк", - дип җавап бирде. Пәйгамбәребез (с.г.в.) егеткә шул телне өйрәнергә кушты һәм егет аны 17 көндә өйрәнде. Ягъни дини зарурият булу сәбәпле, динне тарату өчен башка телне өйрәнергә рөхсәт ителә. Фәкать шул шарт белән. Гомәр (р.г.) әйтте: "Йолдызлар гыйлемен өйрәнегез - юлларны белер өчен. Нәсел-нәсәбегезне, үзегезның кайдан чыкканыгызны, нинди халыктан булуыгызны, телләрегезне өйрәнегез - бер-берегезгә якынайта торган сәбәп булсын өчен". Үз ата-бабаң телен санга сукмау, аны өйрәнмәү - ул инде татар, башкорт-мөселманнардан ерагайта, ә икенче бер чит милләткә, мөселман булмаганнарга якынайта.

**Рәфыйк хәзрәт МИҢНӘХМӘТОВ,**
**Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре имам-мөхтәсибе,**
**Татарстан Республикасының көнчыгыш төбәге казые**

# *Мәктәпләрдә татар теле "исән кала"*

**1 сентябрьгә кадәр санаулы көннәр генә калып бара. Яңа уку елында безнең балаларыбыз татар теле һәм әдәбияты дәресләрен ничек укыячак? Казан шәһәренең мәгариф идарәсе башлыгы урынбасары Илнар Һидиятов әлеге һәм башка сорауларга җавап бирде.**

- Алдан ук шуны әйтәм, 2011-12 нче уку елында татар теле һәм әдәбиятын укытуда артык үзгәрешләр юк, - дип белдерде Илнар әфәнде. - Татар теле дә, татар әдәбияты да Татарстан Республикасының базис уку планына керәләр, шуңа күрә тулысынча федераль базис уку планы белән туры китерелгән.

**- Татарстан мәктәпләрендә туган телне өйрәнүгә атнасына ничә сәгать бүлеп биреләчәк?**

- II сыйныфтан IX сыйныфка кадәр, республикабызның дәүләт телләре булган татар һәм рус телләре тигез күләмдә өйрәнелә: II-VIII сыйныфта - атнасына өч, IX сыйныфта - ике сәгать. Башлангыч сыйныфларда татар телендә әдәби укуга, V сыйныфтан алып - IX сыйныфка кадәр татар әдәбиятына атнасына ике сәгать куелган. Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган учреждениеләрдә һәм рус этномәдәни компонентлы мәктәпләрдә татар әдәбияты дәресләре, узган елдагыча ук, бер сәгатькә киметелгән.

**- Ә югары сыйныфлар белән эшләр ничек тора соң?**

- IX-XI сыйныфларда "Татар теле" һәм "Татар әдәбияты" фәннәре мәҗбүри укытылырга тиешле фәннәр рәтенә кертелгәннәр һәм "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турындагы" ТР Законының үтәлешенә нигезләнә. Әлеге сыйныфларда татар теле һәм әдәбияты сәгатьләре саны профильләренә карап, атнага 3 яки 8 сәгать тәшкил итә. Аның бер сәгате - татар теле, ике сәгате - татар әдәбияты. Филологик профиль буенча укучылар өчен, икенче вариант каралган: 3 сәгать татар теле һәм 5 сәгать татар әдәбияты.




**- Татар телен татар һәм башка милләттән булган балаларга укытуда аерма бармы?**

- Татар телен үзләштерү өчен сәгатьләр саны балаларның милләтенә карап куелмый. Барлык балалар да Тукай телен тигез күләмдә үзләштерә. Бары тик укыту методикасында гына аерма бар. Рус телле укучыларга татар телен өйрәтү коммуникатив методка нигезләнгән. Дәресләрдә укытучылар аралашуның төрле ситуацияләрен тудыра. Сөйләм эшчәнлеге төрләрен оештыруга аеруча зур игътибар юнәлтелә. Гомумән, безнең республикада татар телен укыту өч юнәлештә алып барыла: 1) татар мәктәпләрендә татар теле һәм татар әдәбиятын укыту; 2) рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле һәм татар әдәбиятын укыту; 3) рус мәктәпләрендә укучы рус телле балаларга татар теле һәм татар әдәбиятын укыту. Барлык дәреслекләр дә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган.

**- Яңа федераль дәүләт стандартлары белән бәйле рәвештә, татар телен һәм татар әдәбиятын ни көтә?**

- Чыннан да, яңа уку елында, I сыйныфтан башлап, икенче буын федераль дәүләт стандартларына күчеш башлана. Беренче сыйныфлар өчен уку-укыту методик комплекты эшләнгән. Ул "Перспектив башлангыч мәктәп" дип атала. Әлеге комплектка, федераль дәрәҗәдә расланып, татар теле һәм татар әдәбияты да кертелгән. Димәк, безнең тел мәктәпнең белем бирү системасыннан беркая да китми.

**Роберт БОЛГАРСКИЙ,**
**etatar.ru сайтыннан алынды**

**Балык бистәсе район халкы элек-электән динебезне үз итеп, аның кануннарын төгәл үтәп яшәгән. Авылларда бүген 45 мәчетнең көйле эшләве шуның ачык мисалы булып исәпләнә. Базар икътисады шартларында мәчетләр ничек яши соң? Алар авыл халкы һәм балалар арасында нинди эшләр алып бара? Район имам-мөхтәсибе Сәүдахан хәзрәт Гайнетдиновтан шулар хакында кызыксындык.**

# ХАЛКЫБЫЗ ДИНИ БЕЗНЕҢ

- Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Быел район үзәге мәчетенә имам-хатыйб итеп сайлануыма тугыз ел тулды. Шушы вакыт эчендә күңелгә ятышлы күләмле эшләр башкарылды. Иң сөендергәне: халкыбыз һәм аеруча яшьләр иманга тартылдылар, дин нигезләре белән кызыксындылар. Мисал өчен, 1998 елда Балык бистәсе мәчетенә җомга намазына 18-20 кеше йөргән булса, бүгенге көндә бу сан күпкә артты. Мәчетебездә һәр җомгада 160-180 кеше килеп гыйбадәт кыла. Арада өлкәннәрнең генә түгел, яшьләрнең дә күп булуы - сөенечле хәл. Чөнки гыйбадәт йортына йөргән әлеге егетләр бервакытта да начар юлга басмаячак. Аларның кеше рәнҗетмәүләренә, бозыклыклар кылмавына иманым камил.

- Бүген берәүне дә үгетләп кенә мәчеткә, дингә тартып булмый бит. Сез моңа ничек ирешәсез соң?

- Күп нәрсә гаиләнең имин, тыныч, тәртипле булуына бәйле. Безнең мәчет каршысында 15 елга якын инде яшьләребезгә әхлак тәрбиясе бирү, дин нигезләренә өйрәтү түгәрәкләре эшләп килә. Бу авыр һәм җаваплы хезмәтне Казан шәһәрендәге "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлап кайткан мөгаллимәләребез Наилә Садретдинова, Рокыя Фәсхетдинова, Раушания Мөхәммәтгалимова, Фәнис Нуриәхмәтов намус белән башкара. Аларның һәркайсы 18-20 балага дәрес бирә. Белгәнебезчә, укучыларны дөньяви белемнәреннән соң кабат мәчеткә җәлеп итү бер дә җиңел эш түгел. Әлеге мөгаллимнәребез балалар белән бик файдалы һәм кирәкле эш алып бара. Аларның үз хезмәтләрен белеп, җан-тәннәре белән эшләве нәтиҗәсендә сәбәпсез килми калучылар да сирәк була. Мәчеткә йөрүче балалар һәм мөгаллимәләрнең тәкъдим-фикерләрен искә алып, мәчет янәшәсендә йорт җиткездек. Анда бүген менә дигән спортзал эшли. Мәчет каршында оештырылган түгәрәккә йөргән бик күп егет һәм кызлар урта мәктәптән соң үкенмәслек һөнәр сайлыйлар. Алты егетебез Россия ислам университетын тәмамлады. Бүген дә берничә егет һәм кыз анда белем ала. Әнә шуның нәтиҗәсе буларак, район үзәге һәм авыл мәчетләренә яшьләр дә бик теләп йөри.

- Балалар белән эшләү авылларда ничегрәк тора? Шул хакта да берничә сүз әйтсәгез иде?

- Районыбызның иң эре торак пунктларының берсе булган Котлы Бөкәштә күп еллардан бирле инде әхлак тәрбиясе түгәрәге уңышлы эшли. Бай тәҗрибәле мөгаллимәбез Рәмзия Нуретдинованың хезмәтен бүген күпләргә үрнәк итеп куярга мөмкин. Аның түгәрәгенә йөргән балалар районда гына түгел, республика күләмендәге бәйгеләрдә дә актив катнашалар һәм җиңү яулыйлар. Узган ел Чаллы шәһәрендә Коръән уку бәйгесендә дә алар җиңүче булды. Дини түгәрәкләргә йөрүче балалар белән районыбызда күп төрле мавыктыргыч уеннар, бәйгеләр оештырыла. Җиде ел инде район үзәге мәчетендә лагерьлар эшли. Аның соңгы көнендә балалар белән ямьле Сабантуй бәйрәме үткәрелә. Әлеге бәйрәмдә район хакимияте хезмәткәрләре дә актив катнашалар.

- Сәүдахан хәзрәт, районда 45 мәчет бар, дидегез. Шулардан кайсысылары халык белән нәтиҗәле эшли?

- Барлык мәчетләрдә дә дини бәйрәмнәребезне, гореф-гадәтләребезне төгәл үтәп зур эшләр башкарыла. Быел унбер авыл мәчетендә халыкның матди ярдәме белән балалар лагерьлары эшләде. Анда алар ике мәртәбә кайнар аш белән тәэмин ителделәр. Ә инде соңгы көндә Сабантуй оештырылды. Күңелле уеннар, спорт бәйгеләре үткәрелде. Мондый чараларны Яңавыл имам-хатыйбы Рамазан хәзрәт Хисаметдинов аеруча оста башкара. Иске Арыштан Ринат хәзрәт Абдуллин, Тәберле Чаллыдан Мансур хәзрәт Сафин, Ыргадан Салихҗан хәзрәт Әхмәтшин, Корноухово авылыннан Таһир хәзрәт Хәлиуллин эшчәнлекләрен бүген мактау сүзләре белән генә телгә алырга мөмкин. Алар авыл кешеләре һәм яшүсмерләр арасында зур күләмле тәрбияви эш алып баралар. Авыл имамнарының эш-гамәлләре күпкырлы. Авыл мәчетен тәртиптә тоту, халыкка дини тәрбия бирү белән бергә алар гореф-гадәтләребезне уңышлы дәвам иттерәләр. Никах уку, сабыйга исем кушу чаралары да олылап оештырыла.

- Сәүдахан хәзрәт, әңгәмәбезне йомгаклап, изге Рамазан аенда башкарган кайбер эшләр һәм алда торган бурычлар хакында да әйтеп үтсәгез иде?

- Әйе, һәрбер авыл мәчетендә һәркөнне диярлек ифтар мәҗлесләре үткәрелә. Халкыбыз дини безнең. Ата-бабаларыбызның данлы эшләрен уңышлы дәвам иттерәбез. Һәр йортта диярлек авыл кешеләре ураза тоталар. Бу чарада яшьләр дә актив катнаша. Белгәнебезчә, безнең динебез чисталыкка, әдәпкә, тәртипкә өйрәтә. Намазга баскан егетләр-кызлар бервакытта да җинаять кылмас. Соңгы елларда инде гомер-гомергә башка милләт вәкилләре яшәгән төбәкләрдә дә мәчетләр калкып чыга. Һәр иртәдә барлык җиһанга изге азан тавышы яңгырый.

**Идрис АМЕТОВ,**
**Балык Бистәсе районы**

# Яшьләр гыйлемгә омтыла



***Актаныш районы Киров авылы кызы Айгөл Сабитова узган ел, IX сыйныфны тәмамлагач, Казан шәһәрендә мәдрәсәгә укырга керде. Зәңгәр мәчет каршында күптән түгел генә кызлар өчен ачылган Зәңгәр мәдрәсәдә гыйлем ала ул. Дини белем йортында укыганда кыз үзендәге үзгәрешләрне күреп үзе дә сөенә. Аның дөньяга карашы бик күп яшьтәшләреннән аерылып тора.***

18 яше дә тулмаган кыз белән аралашканда әңгәмәдәшләре аңа тормышта зур тәҗрибә туплаган, олыларча фикерләгән кешегә караган кебек карыйлар. Аның тормышын иплелек, гамьлелек нуры бизи.

Тәрбия гаиләдән бирелә. Мәктәп-бакчалар, иҗтимагый даирә шул тәрбияне көчәйтергә генә сәләтле дип уйлыйм. Айгөлнең дә әти-әнисе ягыннан якыннары – мөселманнар. Ислам дине шартларын үтәп яшиләр. Кызны да намаз укырга алар өйрәтә. Ә мәдрәсәгә ул Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Руслан хәзрәт Мортазин тәкъдимен кабул итеп аяк баса.

Тора-бара әнисе Ләйсән Сабитова да кызы янына Казанга күченә. Ул Зәңгәр мәчеткә пешекче булып эшкә урнаша. Биш вакыт намаз укый, дини йолаларны үтәп, кызына олы терәк булып яши. Айгөл имтиханнарын уңышлы тапшырып, җәйге практикасында туган ягына кайтты. Җәмигъ мәчетендә оештырылган дини аланда балалар укытты ул.

- Пәйгамбәребез (с.г.в.) Аллаһы Тәгалә кануннарын, Коръәни-Кәримне өйрәнеп, шуны кешеләргә җиткерүчеләрне иң хәерле кешеләр, дигән. Иң саваплы эш бу. Балалар белән аралашу, үзем белгән кадәр дини мәгълүматларымны алар белән уртаклашу бик ошады. Бу - минем беренче дәресләрем иде. Дини аланга йөрүче кызлар гарәп хәрефләрен кызыксынып өйрәнде. Малайлар шулай ук практикага кайткан Рөстәм хәзрәттән дәресләр алды, - ди Айгөл.

**- Айгөл, мәдрәсәдә укуның тәртипләрен аңлап та бетермибез, анда да гамәли күнекмәләр үтү мәҗбүри итеп куеламы? Сез мәдрәсәдә нинди тәгълиматлар өйрәнәсез?**

- Иң беренчесе - дин. Ислам дине һәм иман шартларын өйрәтәләр. Бер үк вакытта гарәп хәрефләрен үзләштерәбез, Коръән укыйбыз. Коръәнне дөрес итеп укырга өйрәнү - шәкертләргә куелган төп таләпләрнең берсе. Ә сүрәләрне ятлау аерым дәрес буларак керә. Бер елда үзгәрүен гыйлеменә, тәртибенә, кешеләргә карата мөнәсәбәтенә карап билгеләп, алты укучыга гына практикага юллама бирелде.

**- Мәдрәсәдә ничә ел укыйсы?**

- Дүрт елның баштагы өч елын Казанда, соңгы елны Төркиягә барып уку каралган. Быел, беренче елдан соң ук, Төркия мәдрәсәсенә барып укырга мөмкинлек чыкты. Әмма мин, бик озак уйланганнан соң, Казанда калырга булдым, Төркиягә барырга өлгерермен әле.

**- Укуы авырмы?**

- Мәдрәсәдә укуны җиңел дип әйтмәс идем. Туганнар белән аралашырга да вакытыбыз калмый. Биш вакыт фарыз намазны, җомга намазын, башка намазларны мөгаллимәләребез белән бергәләп укыйбыз. Авырлыкка түзә алмыйча мәдрәсәдән китүчеләр дә бар. Без дә кырык укучы идек, егерме кыз гына калдык. Ләкин тырышып укыганнарга имтиханнар вакытында Аллаһы Тәгалә үзе ярдәм итә. Күпчелегебез Төркиядә белем алган остазлардан, ә безнең төркем төрек кызыннан гыйлем ала. Остазларыбыз куйган таләпләрнең дингә йөз тотуда дөрес юл күрсәтүдән икәнлеген аңлыйбыз. Авыр булса да, укулар бик күңелле. Башка милләт кызлары белән аралашабыз, телләр өйрәнәбез. Арабызда татарлар гына түгел, азәрбайҗан, үзбәк, таҗик, хәтта рус кызлары да бар.

**- Рус кызлары?..**

- Ислам динен кабул итүчеләр алар. Безнең төркемдә Хабаровскидан күченеп кайткан Хәдичә апа укый. Чын исеме Дарья булган. Ислам диненә күчкәч, исемен алыштырган, шәригать кануннары буенча киенеп, яулык ябып йөри. Аллаһы Тәгаләнең кешеләргә иң соңгы дин итеп ислам динен җибәргәнен Хәдичә апа аңлап алган. "Безнең Хабаровскида мөселманнар бик аз, яулык бәйләп йөрүчеләр юк диярлек. Миңа да, дусларым, туганнарым янына кайткач, авыр булачак, әмма яулыгымны салмаячакмын", - дип кайтып китте ул җәйге ялга.

**- Бер айга якын Актаныштa яшәгәндә нинди уй-фикерләрең туды?**

- Мөселманча киенгән хатын-кызларны урамда еш күрергә туры килде, бик сөендем моңа. Мәчеткә дә киләләр. Шулай да Казанда хатын-кызларның, мәчеткә кереп, намаз укып чыгуы гадәти хәл кебек, ә монда күбрәк өйләрендә укыйлар. Намазга басучылар арасында яшьләр дә, өлкәннәр дә бар. Күпләр дингә хөрмәт белән карый. Арада төрле кеше бардыр, билгеле. Беркөнне урамнан узып баручы берәү мөселманча киенүемне гаеп иткәч, күңел әрнеде, кайтып елап алдым. Ләкин Актаныштa Аллаһы Тәгаләгә ышаналар, дингә керүчеләр, мәчеттә, намаздан соң калып, вәгазь тыңлаучылар дә артыр.

**- Айгөл, гомумән, нәрсә соң ул дин?**

- Дин - ул акыл иясе булган ир вә хатынны дөнья вә ахирәт бәхетенә ирештерә торган илаһи бер канун. Динне кабул итү, иман ышанудан тора.

**- Ходайдан бик ялварып сорап та, теләгең кабул булмаска мөмкинме?**

- Ходайдан сорарга кирәк, кабул булмаса да, савабы зур аның.

Айгөл Сабитова белән сөйләшүдән күңелнең сафланып киткәнен тойдым. Бу дөньяга гомерлеккә килгән кебек хис итеп яшибез икән лә без күп вакыт. Әрепләшәбез, бер-беребезне рәнҗетәбез, мәңге җитмәстәй әрсезләнеп, мал җыябыз, исраф итәбез. Айгөл кебек мөслимәләрдән күп нәрсәгә өйрәнәсе бар әле. Үзе ул, 20 яше тулып, паспортын алыштырганда исемен Рабия дип үзгәртергә ниятләвен дә әйтте. "Рабия - Аллаһның колы дигән бик тирән мәгънәгә ия исем", - дип аңлатты. Әйе, гыйлем белән гамәл тәңгәл килгәндә, кеше хикмәтле көчкә ия.

***Филиза СӘЛАХОВА,***
***Актаныш.***

**Рамазан ае - мөселманнарның изге ае. Шушы айда Аллаһы Тәгаләдән Коръән иңгән. Шуңа күрә Рамазан аен кеше Аллаһы Тәгаләгә күңеле белән якын килеп, ураза тотып уздырырга тиеш. Ураза тоткан кешенең күңеле сафланып, акылы ачылып китә.**

# Рамазан – дуслык, кардәшлек бәйрәме

***(Мәктәпләрдә Ураза бәйрәмен үткәрү өчен сценарий)***

Рамазан бәйрәме - безнең бу айның аеруча изге көне. Ул өч көн үткәрелә. Бәйрәм көннәрендә бөтен җирдә туганлык хисе хөкем сөрә. Бу көннәрдә бер-берсенә үпкәләгән кешеләр килешәләр, дуслар очрашырга, туганнар бер-берсен йөреп чыгарга, һәркем әти-әнисенең хәлен белергә тиеш. Ятимнәр, фәкыйрьләр, бәхетсезлеккә очраган кешеләр дә игътибардан читтә калмасын. Бәйрәм көнне елаган күзләр көләргә, авырулар - күңелләренә юаныч алырга, нәниләр сөенергә тиеш. Бу бәйрәм кешеләрдә саф күңеллелек, чисталык, пөхтәлек, миһербанлылык, игелеклелек кебек иң матур һәм кирәкле сыйфатларны тәрбияли.

Зал бәйрәмчә бизәлгән. Алгы планда мәчет рәсеме ясалган, догалар язып эленгән, бер якта өй сурәтләнгән, ризыклар белән өстәл куелган.

Магнитофон язмасында "Изге Рамазан" (Н.Яхина сүзләре һәм көе) җыры башкарыла.

(Милли кием кигән балалар залга кереп басалар).

Алып баручы. Хәерле кич, хөрмәтле кунаклар, әти-әниләр! Без сезнең белән бүген Рамазан бәйрәменә җыелдык. Бәйрәмебез мөбарәк булсын!

**1 нче бала.** Җилфердәсен динебезнең
Яшел ефәк байрагы.
Рамазан - дуслык, туганлык,
Зур кардәшлек бәйрәме!

**2 нче бала.** Рамазан ае килде,
Зурлап сәламен бирде:
Әссәламегаләйкем,
Изге кешеләр! - диде.

*(Балалар "Әссәламегаләйкем" җырын (Г.Садә шигыре, Р.Әхиярова көе) башкаралар).*

**3 нче бала.** Изге Рамазан ае -
Бик мөбарәк бер айдыр.
Аның башы - рәхмәт,
Уртасы - гафу итү, кичерү,
Ахыры - җәһәннәм
Газабыннан котылудыр.

**4 нче бала.** И мөселман кардәшләр,
Динебезне тотыгыз!
Рамазан айлары җитте.
Уразалар тотыгыз!

**5 нче бала.** "Бисмилла", - диеп,
Телне ачыйк таңда.
Йөзне борып кыйбла ягына.
Аллаһы Тәгаләнең биргән көнен зурлап,
Иман нуры җанда кабына.
- Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!
Хөрмәтле кунаклар!

**6 нчы бала.** Әссәламегаләйкүм вә рахмәтүллаһи вә бәрәкәтүһү! Мөселманнар шатланып көтеп алган изге Рамазан аебыз җитте.

**(Ахыры 7 нче биттә.)**

# ИҢ БӘРӘКӘТЛЕ ВАКЫТЛАР...

***Рамазан ае. Барлык җиһанда иң бәрәкәтле вакытлар хөкем сөрә. Мәрхәмәтлелек, изгелек – болар барысы да мөселманнар өчен таныш хисләр. Ә Рамазан аенда бу хисләр тагын да ныгый һәм камилләшә.***



Ураза аен авылда каршылавыма башта берникадәр эч пошыру белән караган идем. Чөнки тәравих намазларына йөреп булмый, Казандагы ифтарлар кала, аралашу кими. Чынлап торып уйлаганда, син үзең өчен нәрсә хәерле булганын белеп бетермисең, барысын да Тәрбиячебез Аллаһы Тәгалә белүче. Киресенчә булып чыкты - авыл җирендә ураза ае бигрәк тә күңелле һәм рәхәт үтә икән. Әни янында рәхәтләнеп бергәләп сәхәрләргә торасың. Авылда шунысы да кызык: торгач, тәрәзәдән бер кат авылны барлыйсың, кемнәр торган икән сәхәргә, көн саен уразада булган кеше тормаган булса, авырып ятмыймы икән дип, көндез барып, хәлен белеп киләсең. Төн пәрдәсен әле таң алыштырмаган вакытта йорттагы утлар бигрәк тә ачык булып күренә.

Аннан соң көн дәвамында әни әлләни артык эш тә эшләтми, җиңелчә генә йөреп, бакчага чыгып, хозурланып, ял итеп йөрисең. Кичке ифтарга әзерләнәсең. Балык бистәсе районның Күгәрчен авылында ифтар ашларына бик тырышып әзерләнәләр. Авылда ике мәчет мәхәлләсе эшләп килә. Анда йөрүчеләрне көн саен чиратка салып, ифтар ашларына чакыралар. Рамазан башланганчы исемлек әзер була - кем кайсы көнне алып кала ала, бүген-иртәгә кемнәр ифтар үткәрә. Олы яшьтәге әбиләрне дә авыз ачу ашларына җыю авылда матур гадәт булып кергән. Яшь кызлар да үзләренең иптәшләре белән җыелып, авыз ачтыралар, тәравихларга баралар, берәү дә үпкәләп калмый. Һәр кеше үз ише белән. Ә район үзәгендә исә, төрле яшьләрдәге кешеләр өчен аерым көннәрдә авыз ачу мәҗлесләре оештыралар, бер көнне - ураза тоткан сабыйлар, икенче көнне - хатын-кызлар, аннан ир-атлар. Аларга тәмле ашлар, җиләк-җимешләр әзерлиләр, мәхәллә халкы шулай кунак уздыра.

Шулай итеп, күңелле генә Рамазан аеның соңгы ун көнлегенә кердек. Бу - уттан котылу көннәре. Мөселманнар өчен бигрәк тә мөһим көннәр. Бу көннәрдә бер-беребезгә карата мәрхәмәтлелек, изгелек нурларын гына өләшсәк, яхшы булыр иде. Аллаһы Тәгалә һәрберебезнең уразасын кабул итеп, аның әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсә иде.

**Гөлсәрия НӘБИУЛЛИНА,**
**20 нче гимназиянең татар һәм инглиз телләре укытучысы.**
**Казан шәһәре**

---

# Дини аланда – ифтар ашы

## Мәчеттә начарлыкка өйрәтмиләр

***Рамазан ае башланып озак та үтмәде, 2-3 яшьтән алып 13-14 яшькәчә балалар, сөенә-сөенә, мәчеткә авыз ачу мәҗлесенә җыелды. Бары тик балалар өчен генә оештырылган ифтар ашында алар шәригать кушкан фарыз гамәлләрне үтәргә тырыштылар. Бисмилла әйтеп авыз ачканнан соң, Аллаһ йортында имамлык итүче Рәмис хәзрәт белән бергәләп барысы да ахшам намазы укыды. Аннары Чаллы каласында яшәүче авылдашлары Әлфәрит Нәбиев һәм аның туганнары тарафыннан әзерләнгән кайнар ашлар белән тукландылар.***



Өстәлгә төрле яшелчәләрдән ясалган ризыклар, җиләк-җимешләр һәм башка тәмтомнар куелган иде. Изге айда балаларны куандыру - ихлас күңелле мөселманнарга хас күркәм сыйфатлар ул. Кечкенәдән шулай Аллаһы Тәгаләнең барлыгына ышанып, аңа сыенучы бу балалар Актаныш районының Күҗәкә авылыннан. Күпләре әти-әниләре белән читтә яшәсәләр дә, җәйләрен биредә әби-бабайлары янында уздыралар. Ә монда ел саен җәйге дини алан эшли. Анда гарәп хәрефләре өйрәтелә, шул ук вакытта Коръән сүрәләре өйрәнәләр, намаз уку тәртибенә төшенәләр. Беренче елны, 2004 елда, анда алтмышлап бала җыелган иде. Быел да мәчеттә җәй буе диярлек эшләгән дини алан 40 баланы сыендырды.

Күҗәкәдә дини лагерь беренче тапкыр моннан 8 ел элек дини гыйлемгә ия Руслан хәзрәт Мортазин тарафыннан оештырыла. Шуннан бирле балалар, аларның әти-әниләре, әби-бабайлары аның ачылуын көтеп алалар. Чөнки аңа шәһәрдән кайткан балалар да йөри. Авылда яшәүче әби-бабайлары, хәзрәтләргә рәхмәтләрен килеп әйтеп китәләр. Оныкларының начар юлда йөрмәвенә сөенечләре зур. Мәчеткә барам дип чыгып китеп, башка җирдә йөрмиме, биредә нәрсәгә өйрәтәләр дип һәрдаим кызыксынып торырга да тырыша.

Күҗәкә авылы имам-хатыйбы Рәмис Гыйльметдинов үзе дә кайчандыр шушы Халидә мәчетендә Руслан хәзрәт Мортазиннан башлангыч дини гыйлем үзләштергән, намаз укырга өйрәнгән. IX сыйныфны тәмамлаганнан соң, Чаллының "Әбүзәр" мәчете каршында эшләүче мәдрәсәдә ике ел укый. Аннары ул Мәскәү ислам университетына укырга керә. Узган ел читтән торып укуга күчеп, туган авылына эшкә кайта.

"Иң яхшы тәрбия - ислам тәрбиясе. Мәчеттә начарлыкка өйрәтмиләр. Ананы хөрмәтләү турында да сөйләшәбез. "Җәннәт - аналарның аяк астында", - дигән Пәйгамбәребез (с.г.в.). Мәчеткә килгән баланың йөзе нурлы, күзендә өмет бар", - ди Рәмис хәзрәт.

Малайлар-кызлар бер-берсе белән аралаша, уеннарның да ямен таба. Мәчеткә алар велосипедлары белән килә, аларны койманың буеннан-буена матурлап тезеп куя. Кызлар иртәнге сәгать тугыздан унбергә кадәр укый, ә малайлар унбердән көндезге бергә кадәр биредә булалар, өйлә намазына калып, намаз укырга өйрәнәләр.

Чаллыда яшәүче Әлфәрит Нәбиев, Күҗәкә авыл җирлеге башлыгы Рамил Хәйбиев бирегә йөрүче балаларны тәмле ризыклар белән һәрдаим сөендереп торалар. Чәй эчүләрне сәдака хисабыннан да оештыралар. Әле бала гына бит, көн дә икешәр сәгать буе уку белән генә шөгыльләнсәләр, кызыксынулары да кимер иде. Шуңа күрә табигатькә чыгып, шашлык пешереп ял итү кебек чараларны аеруча көтеп алалар. Менә шулай дини һәм дөньяви кызыксынулар балаларның җәйге ялын күңелле дә, файдалы да уздырырга ярдәм итте.

Мәчеттә чиста, якты. Узган ел газ кертелде. Кышын җылы була. Суы кергән. Мәхәллә хисабына быел тәһарәтханә бүлмәсе төзелә башлады. Изге йорт иман байлыгын тагын да арттырсын, күңел дәфтәрләренә изге гамәлләр генә язылсын.

**Филиза СӘЛАХОВА,**
**Актаныш.**

---

# КИЛӘСЕ РАМАЗАНГА КАДӘР!

**Татарстан җирлеге - Россиядә иң күп мәчетле, иң күп шәкертле, ислам дине үсешенә зур игътибар бирүче төбәкләрнең берседер. Дөрестән дә, мәчетләр саны да, намаз укучы, ураза тотучы, дин белеме алучы мөселманнар да бездә елдан-ел арта бара.**

Кукмара районында да шактый күп авылларда иманлы, ихластан гыйбадәт кылучы халык яши. Аллаһы Тәгалә кушканнарын үтәп, тыелганнан тыелып гомер итүче шушы якташларыбыз тормышында көндәлек эш-гамәлләр намаз уку, мәчеткә йөрү, дини белем алу белән үрелеп бара. Аш-Бужи, Уразай, Туембаш, Зур Сәрдек һәм башка авылларда яшәүче мөселманнар: "Намаз эшне калдырмый, киресенчә - бәрәкәт кенә өсти", - дип әйтә...

Күптән түгел Өркеш авылына барырга насыйп булды. Рамазан аеның 13 нче көнендә биредә кызлар өчен оештырылган җәйге мөселман лагеренең ябылу чарасы үткәрелде.

Менә инде берничә ел рәттән Фәния һәм Рәшит Җәләлиевлар гаиләсе оештырып килгән әлеге лагерь Өркеш балаларын гына түгел, күрше авыл вә төбәкләрдән, шулай ук шәһәрдән җәйге каникулга кайткан яшүсмерләрне үз канаты астына җыя. Җәләлиевларның "Фәниябикә мәдрәсәсе" буларак мәгълүм булган шәхси йортлары һәр җәйне ял итү, гыйбадәт кылу һәм дини белем алу үзәгенә әверелә. Төп шәкертләр булып мәктәпнең өлкән сыйныфларында һәм югары уку йортларында укучы кызлар саналса да, мәдрәсәне авыл бала-чагасы да, пенсия яшендәге абый-апалар да үз итә икән.

"Фәниябикә" мәдрәсәсе бик күркәм табигатьле урында урнашкан. Җан ризыгы эзләп килүче кызлар биредә дин белеме дә ала, гаҗәеп табигать манзарасы илә дә хозурлана, фикердәшләре белән дә аралашып, рухи мәгънәдә ныгый, сәламәтләнә.

- Биредә кичләрен бигрәк тә матур, күңелле, - ди кызларның берсе. -Ахшам намазын укыгач, авыз ачтык, бергәләп ифтар мәҗлесендә катнаштык.

- Ә миңа сәхәр вакыты, иртәнге намаз укылган чак бит тә ошады. Табигать уянып кына килгән шушы сәгатьтә без инде аякта идек - тәһарәт алып, намазга әзерләндек, җәйге авылның уянуын күзәттек.

Гөлчәчәк Харисова, Чулпан Баһаветдинова, Зилә Сәмигуллина бирегә инде икенче елларын киләләр икән.

- Бик күңелле булды, - ди кызлар. - Ял да иттек, белем дә алдык. Тырыша торгач, бөтен Коръәнне гарәпчә укып чыктык (хатем кылдык), ахырда мәрхүмнәребезне искә алып багышладык.

Лагерьны ябу тантанасы табигатьнең гүзәл почмагында - тау-калкулык итәгендәге су буенда үтте. Җыенга күпләп килгән авыл халкы һәм читтән чакырылган кунаклар ярымтүгәрәк итеп тезелгән эскәмияләргә урнашты. Иң элек Коръән аятьләрен укып, дога кылдык. Мәҗлесне алып баручы кардәшебез Фәрит Галәветдинов тирән мәгънәле шигъри юллар белән халыкны сәламләгәннән соң, сүз район имаммөхтәсибе Зиннур хәзрәт Сәмигуллинга бирелде. Ул җыенда катнашучыларны тәбрикләде һәм Рамазан ае фазыйләтләре хакында үтемле вәгазь сөйләде.

- Быелгы ураза озын һәм эссе җәйге көннәргә туры килде, әмма ихласлы бәндәләренә Аллаһы Тәгалә җиңеллек бирә, - диде Зиннур хәзрәт. -Ураза тотып, без үзебезне тәрбиялибез, нәфесләребезгә хуҗа була алуыбызны раслыйбыз. Изге гамәлләрнең савабы җиде йөзгә тапкырлана торган әлеге чорны игътибарсыз калдырмасак иде...

Алга таба "Фәниябикә" мәдрәсәсендә җәйге чорда белем алган балалар осталыкларын күрсәтте: кемдер азан әйтте, кемдер Коръән укыды, кемдер мөнәҗәт башкарды. Шулай итеп, читтән килгән кунакларның вәгазе лагерьга йөрүчеләрнең чыгышлары белән үрелеп барды. Айдар Шәрипов укыткан төркемнең чыгышы аеруча зур тәэсир калдырды. Сөбханаллаһ, шактый күп нәрсә өйрәнгәннәр икән.

- Биредә әйтелгән һәр сүз - Аллаһны зикер итүдер. Аллаһы Тәгалә барчабыздан да разый булса иде, - дип җиткерде нәсыйхәтен Айдар хәзрәт.

Лагерь хуҗабикәсе Фәния апаның сеңлесе Әлфия ханым Һадиева башкаруында тирән эчтәлекле, хикмәтле мөнәҗәт яңгырады. Аны башкарыр алдыннан ул: "Мөнәҗәтемне җыр буларак түгел, бер дәрес итеп кабул итсәгез иде", - дигән теләген белдерде.

Җыенның нәни кунаклары - Өркеш һәм Югары Арбаш балалар бакчалары вәкилләре чыгышы да күңелгә уелып калды. Тәрбияче апалары белән бергәләп бик күңелле дә, мәгънәле дә җырлар башкардылар алар.

Түбән Арбаш авылы имамы Мөдәррис хәзрәт, үз вәгазендә үсеп килүче буынны тәрбияләү мәсьәләсен күтәреп, болай диде:

- Балаларыбызны дин әхлагына нигезләнеп тәрбияләсәк иде. Үзебез олыгайгач, моның уңай нәтиҗәсен, һичшиксез, күрәчәкбез. Ә ахирәткә күчкәч, без аларның догаларына бик тә мохтаҗ булачакбыз...

Әйтергә кирәк, җыр-мөнәҗәтләр, вәгазьләрдән тыш, җыен программасында төрле спорт чаралары, уеннар да бар иде. Кечкенәрәк балалар өчен җептән уенчыклар кисеп алу уены оештырылса, өлкәнрәкләр өчен кул көрәштерү, аркан тартышу, гер күтәрү кебек ярышлар тәкъдим ителде. Барлык уен-ярышларда да балалар актив катнашты, фәкать гер күтәрергә генә теләүче егетләр табылмады.

- Ул яшь муллаларны бәлеш ашау буенча ярыштырсаң гына инде! - дип шаяртып алган бер апага күршесе:

- Какуй монда бәлеш - ураза бит! Уразалы килеш бик көчәнәселәре дә килмидер шул...

Гер ярышы буенча төп бүләк спорт тренеры Райнур Гыйльметдиновка бирелгәч, беркем дә ризасызлык белдермәде тагын... Гомумән, бу җыенда бүләк-күчтәнәчләр муллдан өләшенде. Моның өчен оештыручыларга, мәдрәсә җитәкчеләренә күңелдән рәхмәт хисләрен белдерүчеләр күп булгандыр. "Аздан да күңел була", - дип, халык юкка гына әйтмәгән. Күпләр, бигрәк тә балалар, җыеннан бик шатланышып кайтып китте.

Әмма шунысы да мөһим: шушы мәдрәсә, лагерь акча күп булганга күрә оешты дип әйтү - дөрес түгел. Бу эш иң элек зур тырышлык, ихласлык һәм иң әһәмиятлесе - Аллаһ ярдәме булганга башкарыладыр. Әйе, Татарстанда бүген динебезне торгызу, дингә нигезләнеп әхлакый тәрбия бирү өчен яхшы, уңайлы шартлар тудырылган. Әмма бу өлкәдә уңышка ирешү динебез, милләтебез, киләчәгебез өчен ихластан борчылган шәхесләребезгә бәйле. Әлхәмдүлилләһ, Өркештә бу юлда иҗтиһад кылучы хөрмәтле затлар Фәния һәм Рәшит Җәләлиевлар бар. Менә инде ничә ел алар авылда дин торгызылсын, мөселманнар гыйлемле, мәчетле, мәдрәсәле булсын дип тырыша. Аларда булган ихласлык барлык авыл кешеләренә дә күчсә иде.

Хәер, ислам динен чын-чынлап яшәешебезнең нигезе итү эшендә Фәния абыстай белән Рәшит хәзрәт хәзер ялгыз түгел, ярдәмчеләре елдан-ел арта бара. Быел, мәсәлән, мәдрәсәдә үткәрелгән ифтар мәҗлесләренә авыл кешеләре үз өлешләрен кертергә тырышты: кемдер сөт китерде, кемдер бәлеш пешереп алып килде. Аларга, шулай ук Васил Җаббаровка, Илшат Камаловка, Мөнирә апа белән Рамиягә, аш пешерүче Гүзәлгә һәм күп кенә мәшәкатьләрне үз өстенә алган бертуган энеләре Зөфәр Фәйзриевкә рәхмәтләре чиксез аларның.

Мөселман кешесе үз тормыш юлын бер Рамазаннан икенче Рамазанга кадәр хисаплап, тәгаенләп тора. "Фәниябикә" мәдрәсәсе лагеренда ял вакытларын бик файдалы үткәргән кызлар да саубуллашканда: "Киләсе Рамазанга кадәр!" - дип таралышты. Күзләрендә яшь ялтыраса да, алар елмайды, чөнки сафланган йөрәкләре, гыйлембәрәкәткә баеган рухлары яңадан-яңа сөенечле өмет белән тулы иде. "Аллаһның сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булсын сезгә!" - дип, бер-берсенә дәшкән кызлар күңелендә шул мәлдә тормыш офыклары киңәеп китте кебек. Әйе, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте чиксез, аңа лаеклы гына булырга кирәк. Лаеклылар вәкиле булып яшәргә, исән-имин күрешергә насыйп әйләсен!

**Ришат КУРАМШИН,**
**Кукмара**

**Күпләр тормышында иман, дин иң төп аспектларның берсе булып тора. Кешелек тарихы динсезлекнең ахыр чиктә теләсә нинди җәмгыятьне җимерүен һәм таркатуын күрсәтте. Ә инде татарларга килгәндә, бабаларыбыз ислам дине тарафдарлары булуларын меңнан мең елдан да күбрәк элегрәк рәсми төстә исбатлап күрсәтә алды. Шул заманнан бирле соңгы дөньякүләм дин халкыбызны саклауга һәм үстерүгә хезмәт итте. Республикабызда пәйгамбәребез тарафдарлары, барча мөселманнар - һәммә өммәт белән нәрсә була? Киләчәктә мөселманнарга карата стратегияне ничек корырга? Шушы һәм шуңа охшаш сорауларга ачыклык кертүен үтенеп, без сәяси фәннәр докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең иҗтимагый фикер һәм ислам гыйлеме бүлеге мөдире, Россия Ислам университеты ректоры һәм Татарстанның ислам тикшеренүләре үзәге җитәкчесе Рәфыйк әфәнде Мөхәммәтшинга мөрәҗәгать иттек.**

# ТАТАРГА ЙӨЗ ТОТКАН ИСЛАМ

## Безгә нинди ислам дине кирәк?

**- Рәфыйк әфәнде, Татарстанда мөселман өммәте торышын Сез ничек бәяләр идегез?**

- Бар да ал да гөл дип әйтә алмыйм. Узган гасырның 90 нчы еллары башында тормышыбызга ислам диненең әйләнеп кайтуын хуплап каршы алдык, күпкә яхшырак буласына өметләндек. Әмма бар да без көткәнчә булмады шул. Әлбәттә, ул заман белән чагыштырганда, мөселманнар саны артты, тик һәр ялтыраган нәрсә алтын була алмаган кебек... Һәм аның безгә кирәклесе, аны шартлы төстә "татар исламы" дип йөртик, нәкъ менә безнең шартларга яраклашкан булырга тиеш. Мөселман кешесенә хәзерге заман процесслары ниндидер чит-ят күренеш булырга тиеш түгел. Монда сүз диннең асылын үзгәртү турында түгел, ә нәкъ менә безнең менталитетка, тарихка һ.б. бәйлелек турында бара. Мин Татарстанда милли йөзе булган Россия исламы, толерант ислам өстенлек итәргә тиеш, дип саныйм.

Милли проблемалар мөселманнар өчен икенчел дәрәҗәдә сыман үзе, ә чынлыкта, алар җәмгыять эшчәнлегендә көчле фактор булып тора. Һәм бүген без нәкъ шуңа омтылырга тиешбез – ягъни ислам кыйммәтләренә генә әйләнеп кайту түгел, ә инде татарларга, җәмгыятькә хезмәт итә, җәмгыять өчен мөһим булган проблемаларны хәл итә торган дингә кайтырга тиешбез. Үзмаксат буларак булган мөселман түгел, ә җәмгыять өчен кирәк булган мөселман кирәк.

Белем бирү проблемасы бар. Имамнарыбызны үзебездә һәм чит илләрдә укыткан ислам дине белгечләренең күбесе безнең традицияләрдә тәрбияләнмәгәннәр, аларның кайсыберләрен ваһһабчылар дип йөртәләр. Әмма бүген безгә үзебезнең гасырлар буена дәвам иткән дини гореф-гадәтләребезгә төшенү кирәк. Аларда бик күп уңай яклар бар, әйтик, ислам диненең нигезләренә тирәнрәк төшенү өлкәсендә. Безнең дини тәгълимат Россиянең нәкъ кыл уртасында яшәгән шартларда, башка диндәгеләр белән тыныч яшәп, бары тик төпле акылың һәм тирән фикер йөртүең белән генә яшәяеш рәвеше формалаштыруны хуплый. Менә шуңа да безнең борынгы бабаларыбызга бөтен мөселман өммәтенең иң алгы сафында булырга язгандыр да.

Хәнәфи мәзһәбе иң либераль юнәлеш булып тора. Нәкъ менә ул безгә күп конфессияле мохиттә исән-сау сакланып калырга ярдәм итте дә – монысы бик мөһим. Хәнбәлиләр – шундый ук бар яктан килгән, камил мәзһәб, тик күп конфесияле илләр өчен яраклашмаган гына ул. Аларда хокукларларның гадәти чыганагы – халык традицияләре юк. Мондый мәзһәб безгә бу очракта кирәк түгел. Хәнәфи мәзһәбе ислам кануннарына каршы килми торган гадәти хокукларны таный. Мәсәлән, вафат булган кешенең "өчесе"н, "җидесе"н, "кырыгы"н искә алу. Әгәр дә Урта Азиядә әлеге йолалар абсурдлык, акылга җитмәслек дәрәҗәгә җиткерелсә, бездә исә алар артык җәелмичә генә, иң якын туганнары катнашында гына үткәрелә




## Мөселманнарга адекват чынбарлык кирәк

**- Татарстанда ислам гыйлеме бирүгә ни җитми?**

- Россия стандартлары буенча бездә дини уку йортлары бик үк төшеп калганнардан түгел. Россия ислам университетыбыз, "Мөхәммәдия", Ислам динен кабул итүгә мең ел исемендәге Югары мөселман мәдрәсәләре, урта уку йортлары бар. Хәзер аларда дөньяви фәннәр укытуны кертү хакында күп сөйлиләр, тик таякны артык бөгү дә кирәкмидер. Минемчә, монысы иң мөһиме түгелдер. Әлеге мәдрәсәләргә укырга, гомумән, дөньяви мәктәпләрдә белем алган асыл затлар килә бит. Дини булмаган фәннәр турында сүз чыгуга, нигәдер шунда ук җәдитчә мәктәпләрне искә төшерәләр. Әмма бу – татарларда беренче дөньяви белем бирүне булдыру омтылышы гына булган бит – аларга хакимият кенә моны эшләргә рөхсәт бирмәгән. Татарлар революциягә кадәр балаларын русларның православие дине рухындагы мәктәпләргә укытырга бирергә нык курыккан.

Җәдит мәктәпләре менә шулай итеп үзләренең бу миссияләрен үти алмый кала – алардан имамнар тәрбияләнеп чыкмый. Әлеге уку йортларына дин әһелләре булырга теләгәннәр түгел, ә төрле өлкәләрдә белем тупларга теләгәннәр укырга килгән. Алар еш кына тормышта үз урынын таба алмый азапланган, кайберсе хәтта кара эшче булып эшләргә дә мәҗбүр булган. 1905-1907 елгы революцияләрдән соң нәкъ менә алар урамга каршылык акциясенә чыга! "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә нигез салучы һәм аның җитәкчесе Галимҗан Баруди моңа бик нык аптырый: аның мәдрәсәсендә, югыйсә, заманына күрә менә дигән шартлар тудырылган була, ә шәкертләре канәгать түгелләр...

Классик мөселман белем бирү моделе безнең шартларга яраклашмаган. Бүгенге көндә иң мөһиме – нәкъ менә безнең җәмгыять таләпләренә җавап бирә алырлык укыту моделе булдыру.

XIX гасыр уртасына кадәр бездә Бохара укыту системасы гамәлдә иде. Шәкертләр шуңа охшаш уку йортларына йөргән, гарәп, фарсы телләрен, Коръәнне өйрәнгән. Алар әлеге гыйлемне үзләштергән очракта да, Россиянең нәкъ үзәгендә, шәһәрләрдә яшәп, аларны ничек файдаланырга? Рус телен, математиканы белмәгән килеш иң яхшы дигәндә дә мәчеткә имам булып барырга мөмкин, шуннан башка... тагын кая?! Һәм шуңа да әлеге укыту системасын үзгәртергә ниятләгән җәдитләр пәйда була да инде.

## Кадрлар барысын да хәл итә

**- Хәзерге вакытта болар безнең өчен мөһимме соң?**

- Без үзебезнең мирасны да белергә тиеш. Шәкертләребез барысын да – татар тәфсирләрен дә, татар галимнәренең биографиясен дә, татар матур әдәбиятын һәм фәнни карашларын да белергә тиеш. Укытыла торган барлык курслар, яңа дәреслекләр әлеге нечкәлекләрне дә истә тотарга тиеш. Башкача, безнең халыкка, бездәге дин гыйлеменә хас үзенчәлекләрне аңлардай кешеләр әзерләү мөмкин булмаячак.

Әлбәттә, укытуның яңа технологияләрен дә эшкә җигү кирәк. Безнең совет системасы бар кешенең һәр өлкәдән дә белемле булуын күздә тота иде. Шуңа да укучыларыбыз һәртөрле олимпиада һәм конкурсларда беренче урыннарны алып килде. Көнбатышта исә кешене конкрет бер максатка гына йөз тотып әзерлиләр, аерым гамәли эшчәнлеккә караган белемне генә бирәләр. Боларның барысын да игътибар үзәгендә тотып, төпле белем биреп, шул ук вакытта, укучыларга һәм студентларга тиешле юнәлеш бирергә кирәк. Моның өчен, һичшиксез, үз дәреслекләребезнең булуы кирәк, безнең үзебездә безнең җирлеккә яраклаштырылган дәреслекләр булдыру традициясе бар бит.

Ахыр чиктә, бар да квалификацияле кадрлар җитенкерәмәүгә килеп төртелә. Гадәти укучыларга, студентларга, мәхәллә халкына хакыйкатьне аңлаешлы итеп аңлата алырдай белгечләребез аз. Хәзрәтләребез дөньяви галимнәр белән бертигез дәрәҗәдә сөйләшә алырдай белемгә ия түгел.

Безгә мөселман зыялылары да бик кирәк. Хәзерге заман (башлыча, совет рухында тәрбияләнгән) зыялылар өчен ислам – чит-ят булмаса да, аларның карашы диннең асылына төшенелмәгән караш шул.

Мөселман зыялылары – алар имамнар гына түгел. Руханилар йолаларны үтәргә, җәмгыять өчен үрнәк күрсәтергә тиешләр. Ә зыялылар тирән белемле һәм сәяси яктан әзерлекле булырга тиеш. Йосыф Акчура, Садри Максуди – аларның барысы да төпле дөньяви белем алган кешеләр, әмма алар һәр мәсьәләне хәл иткәндә ислам кануннарыннан чыгып эш йөрткәннәр, кылган гамәлләренең һәркайсы мәгънәви булган. Кызганычка каршы, хәзер бу як аксый. Шуңа да хәзер мөселман зыялылары булдыру мөһим.

## Бар да мәхәллә тирәсендә бөтерелә

**- Мөселман татарлары өчен хәзерге көндә тагын нәрсәне иң мөһиме дип саныйсыз?**

- Хәзер бездә мөселман өммәте структурасы инде булдырылган. 1992 елда Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәте, мөхтәсибәтләр, дини мәктәпләр системасы төзелде. Хәзер дини уку йортларының саны тугызга гына калды. Минем карашка, бу – җитәрлек. Билгеле бер вакыттан соң сан сыйфатка күчәргә тиеш, тик әлегә мондый хәл күзәтелми.

Ислам дине өчен иң мөһиме – мәхәллә, тик әлегә ул бездә юк. Хәзер яшьләр дингә тартыла. Рухи вакуум бар һәм ул дин белән тутырыла. Әгәр дә инде мәхәллә булмаса, дини үсеш төрле юллар белән барачак. Әгәр дә бернинди дә хәстәрен күрмәсәк, ахырының аянычлы булуы бар. Хәнәфи мәзһәбе, безнең татар дини тәгълиматы традицияләренең барысы да бөтенләй юкка чыгарга мөмкин.

**- Тагын ун елдан соң нинди мәхәллә булырга тиеш?**

- Һич шөбһәсез, мәхәллә мәчетләр янында төзелергә тиеш. Казанда илледән артык мәчет бар, миллионлы халкы булган Казан өчен бу да әле җитәрлек түгел дип саныйм. Чагыштыру өчен, Мәскәү белән Уфаның һәркайсында дүртәр генә мәчетләр саны күпкә ким. Тулаем алганда, яңа мәхәлләләр төзү принциплары һәм технологиясе әлегә эшләнмәгән, моның белән шөгыльләнәсе бар. Территориаль бәйлелек артык зур роль уйнамаска тиеш, дип саныйм. Шулай ук мәхәллә төзелү белән имам мәсьәләсе дә үзеннән-үзе көн тәртибеннән төшеп кала: дини оешма үз җитәкчесен үзе үк сайлап куя.

## Мөселманнар саны күпме булыр?

**- Тагын 5-6 елдан соң мөселманнар саны артырмы икән?**

- Дөньядагы халыкның 50-70 проценты үзен диндар кеше дип саный. 2001 елда республикабыздагы яшьләр арасында социологик тикшеренү уздырган идек. Аның нәтиҗәләре 80 процент русларның һәм 85 процент татарларның үзен динле кеше дип санавын күрсәтте. Дүрт процентка якыны барлык дини йолаларны үтәп бара икән. Әгәр дә ислам гыйлеме һәм тулаем өммәт үсеше сценарие позитив юл белән барса, ислам диненә ихлас күңелдән ышанган һәм аның аерым йолаларын үтәп барган кешеләрнең саны татарлар арасында ун процентка җитәр, дип уйлыйм. Бу – яңа типтагы мәхәлләләр төзү проектларын эшләп тормышка ашырганда, мөселман интеллигенциясе катламын булдырганда шәкертләрне тагын да камилрәк укыту гамәлгә кергәндә мөмкин эш. Имамнары өчен кайгыручылар моның белән иң беренче нәүбәттә шөгыльләнергә тиешләр.

*Илшат СӘЕТОВ,*
*etatar.ru сайтыннан алынды*
*(Таһир Сабирҗанов тәрҗемәсе)*

## Бәйрәм көнне генә сабый булып торыйм

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

Авыруларга күршеләребезгә, өлкәннәргә игътибарлы, сабыйларга карата кече күңелле булып, кардәшләребез арасындагы мөгамәләбезне яхшырту өстендә эшлибез. Бер-беребезне гафу итеп, Раббыбызның гафуына өметләребезне арттырабыз.

Болай да кыска төннәребезне йокы белән кыскартмыйча, Коръән укып, зикер-тәсбих, нәфел намазларыбыз аша бәрәкәтләндерәбез, ихлас догаларыбыз аркылы Аллаһы Тәгаләдән үзебезгә, балаларыбызга, барлык мөселман кардәшләребезгә тәүфикъ, иман байлыгы сорыйбыз; фәкыйрь-мескеннәргә, авыррак хәлдә яшәүче кардәшләребезгә фитыр садакаларыбызны биреп, Ураза бәйрәмен аларның да күңел күтәренкелеге белән каршылауларын тәэмин итәргә тырышабыз.

Яу кырындагы солдат кебек, үзебез дә, гүя, көрәш мәйданында. Әмма бу – гади көрәш түгел, бу - Аллаһ ризалыгын алу өчен, үз-үзең белән, игъни үз нәфесең белән көрәш. Әлхәмдүлиллаһ, без җиңү юлында: күңелләрдә куаныч, тәннәрдә җиңеллек, телләребездә дә, калебләребездә дә шөкер, күзләребездә - шатлык яшьләре. Тоткан уразаларыбыз сәбәпле, җыйган әҗер-савапларыбызны югалтмыйча, Кыямәт көненә кадәр саклый алсак иде, дигән теләк белән гает көненә дә якынлашабыз, чиксез шөкер.

Гает ул - һәрбер мөселман өчен бөек җиңү көне. Бер ай дәверендә без үзебезнең нәфес-теләкләребезне җиңәргә, Раббыбыз каршында түбәнчелек күрсәтергә, үзара ярдәмләшергә, башкалар турында кайгыртырга, сабыр вә түзем булырга өйрәндек. Әби-бабаларыбыз да шушы җиңү мизгелләрен кичереп сөенгәннәр, без дә әлеге шатлыкны кичерәбез.

Хөрмәтле мөселман кардәшләр! Сабый чакларыбыздан күңелләребездә якты бер хатирә булып уелып калган гает бәйрәмнәре һәрберебезгә шатлык-куаныч кына алып килсен! Бер-беребезгә карата мәрхәмәтле булыйк, әти-әниләребезнең хәлләрен белик; дус-ишләребезне, туган-тумачаларыбызны, балаларыбызны тәмле-тәмле күчтәнәчләребез белән сыйлыйк, бу дөньядан киткән якыннарыбызның каберләрен зиярат кылып, аларга изге догаларыбызны юллыйк. Гаетләребезне һәркемнең, бигрәк тә балаларыбызның, оныкларыбызның күңелләрендә гомер буе сагынып искә алырдай якты эз калдырырлык итеп үткәрик.

*...Уйласаң ул якты көнне, килә күз яшь,*
*Хозур ла соң! инсан өчен бу хәл, бу яшь!*
*Бәйрәм көнне күктән җиргә нурлар ага,*
*Әйтерсең лә чыккан бу көн ике кояш!*

**(Г. Тукай)**

**Алмаз хәзрәт МӘХМҮТОВ.**
**Түбән Кама.**

## Казанда милли киемнәрнең халыкара конкурсы үтә

**Әлеге конкурсның максаты – җәмгыятьтә башка халыкларның милли мәдәниятенә кызыксыну уяту һәм шулай ук татар халкының бай милли мәдәниятен һәм йөзен саклап калу.**

2011 елның 9 сентябреннән 11 сентябренә кадәр Казанда VII Халыкара мөселман киносы фестивале кысалары нигезендә "International fashion" милли киеме буенча III Халыкара дизайнерлар конкурсы үтә.

"International fashion" конкурсы башка халыкларның милли мәдәниятенә кызыксыну уяту максатында үткәрелә һәм дизайнерларның заманча киемнәрне милли стильдә күрсәтер өчен халыкара мәйдан да булып тора.

Конкурста Россиядән һәм башка регионнардан булган атаклы дизайнерлар һәм үзләренең карьераларын башлап кына җибәргән модельләр дә катнаша. "International fashion" катнашучыларны ике буенча да, милли киеме буенча да чикләми. Конкурста тәкъдим ителгән коллекцияләр арасында студент-дизайнерларның диплом эшләрен һәм мода өлкәсендәге белгечләрнең дә милли киемнәр коллекциясен күрергә була. Географик киңлеге ягыннан да конкурс чикләнмәгән һәм дөньяның төрле милли киемен күрсәтү дә күз алдында тота.

"International fashion"- 2011дә үзенең уникаль коллекцияләрен Египет, Йемен, Ливан, Иран шикелле гарәп илләре, Европа илләреннән - Герцеговина һәм Босния, СНГдан - Үзбәкстан тәкъдим итәчәк.

"International fashion" конкурсы милли костюмнарның яшәеш ареалларын киңәйтә, заманча кием модельләренә бүленергә ирек бирә һәм күп санлы дизайнерларны милли мода индустриясендә берләштерә.

Конкурсны оештыручылар булып Татарстан Республикасының Мәдәният Министрлыгы, Казан дәүләт технология университеты ("Дизайн" кафедрасы), "Сөембикә" журналы, дөнья мәдәнияты институты ЮНЕСКО тора. Конкурс Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең дизайнерлар союзы ярдәме белән үтә. "Сөембикә" журналының төп максаты - татар халкының бай милли мәдәниятен һәм йөзен саклап калу.





### "Ромео һәм Джульетта": хәзер татар-style!

Шекспирның мәшһүр трагедиясенең сюжетын Татарстандагы катнаш никахлар темасына чуалдырып фильм төшергәннәр. Картинаның премьерасы VII Казан халыкара мөселман кинофестивалендә тәкъдим ителәчәк.

Ромео һәм Джульетта урынына татар һәм рус милләтле егет һәм кыз. Италиянең Верона шәһәре урынына Татарстан авылларының берсе. Яшь гаилә бәхетле тормыш кичерә, тик беренче туган бала ак тасмаларны каралары белән алыштыра. Сабыйга нинди исем бирергә? Муллага алып барыргамы, попкамы? Шекспир Монтекки һәм Капулетти гаиләләрен баррикаданың капма-каршы якларына куйган кебек, яшь режиссер Алёна Малкова да үзенең фильмында татар һәм рус гаиләсен елганың ике ярында калдыра. Кайсы беренчел - милләтме, мәхәббәтме?

Белеме буенча юрист, казанлы Алёна Машкова соңгы берничә ел кино сценарийлары язу белән шөгыльләнә. "Ромео һәм Джульетта" дип аталган 52 минутлык документаль тасма - яшь режиссёрның һөнәри дебюты. Шекспир әсәренә охшаш итеп ясалган картинаның төп темасы - Татарстанда шактый актуаль булган мәсьәлә - милләтара мөнәсәбәт, катнаш никахлар.

"Ромео һәм Джульетта" трагедиясенең "татар версиясен" Татарстан тамашачысы 6-11 сентябрьдә узачак VII Казан халыкара мөселман кинофестивалендә күрә алачак. Фильмның премьерасы "Татарстанда эшләнгән" дип аталган конкурстан тыш программада тәкъдим ителәчәк.

"Ромео һәм Джульетта" документаль фильмы 2011 елда "Кинолента" студиясендә төшерелгән һәм моңарчы кинофестивальләрдә күрсәтелмәгән. Тәүге тапкыр ул нәкъ менә Казан кинофестивале кысаларында тәкъдим ителәчәк.

***tatartime.com сайтыннан алынды***

## Рамазан – дуслык, кардәшлек бәйрәме

**(Ахыры. Башы 4 нчы биттә.)**

Алып баручы. Быел изге аебыз августта башланып китте. Бу айда теләкләребез кабул булып, Аллаһы Тәгалә өйләребезгә - тынычлык, муллык, гаиләләребезгә - татулык, дуслык, балаларыбызга тулы иман насыйп итсә иде.

Рамазан аенда мөселман кардәшләр ураза тоталар. Нәрсә соң ул ураза? Ураза ул, безнеңчә, тыелып тору. Ураза тотучылар, таң атканнан алып кояш батканчыга кадәр, ашау-эчүдән тыелып торырга тиешләр, аларга тәмәке тартырга, дару эчәргә, начар сүзләр әйтергә, кешегә яла ягарга, ялган сөйләргә ярамый. Сезнең дә, балалар, әби-бабаларыгыз ураза тоталар, намаз укыйлар, ә намазга азан әйтеп чакыралар.

*(Бер малай азан әйтә. Ике оныгын (бер малай һәм бер кыз) ияртеп, әби керә).*

Малай. Әбекәй, азан әйтteләр бит, авыз ачарга вакыт җиткәндер инде.

Әби. Шулай шул, балакайларым, кояш та баеды инде, авыз ачарга вакыт икән.

Алып баручы. Исәнме, әбекәй.

Әби. Исәнме, кызым. Балакайларым, сез монда нишлисез?

Алып баручы. Без Рамазан бәйрәменә җыелдык.

Әби. И шулаймыни!

Малай. Әбекәй, әйдә, авыз ачарга вакыт җитте бит инде.

Алып баручы. Әбекәй, килегез биргә, башта авыз ачып, тукланып алыгыз.

(Әби оныклары белән өстәл янына утыра).

Әби. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! (Әби башта тоз, аннан җимеш каба. Оныклары да шуны кабатлый. Малай белән кыз сөйләшә башлыйлар).

Әби. Нишлисез сез? Ашаганда сөйләшмиләр дип, ничә мәртәбә әйттем мин сезгә, балалар?

Малай. Сөйләшсә ни була, әбием?

Әби. Тамагыгыз тукланмый, ризыгыгызны җеннәр ашап бара.

Кыз. Шулаймыни, әбием, ярар, сөйләшмәбез, алайса. Син туйдыңмы, Фаил? Мин туйдым. (Киерелә).

Әби. Өстәл янында киерелеп утырмыйлар. Балаларым, бервакытта да туйдым дип әйтмәгез, ризыктан туймыйлар. Аллага шөкер, тукландым дияргә кирәк. Тамак туйдыргач, дога кылабыз. Рәхмәт, балалар, ураза бетте инде. Хәзер Рамазан бәйрәме башлана. Без, шатланып, сездә кунак булабыз.

Алып баручы. Әбекәй, утырып кына тыңлап тор, балалар бәйрәмгә матур-матур шигырьләр өйрәнделәр.

(Балалар өйрәнеп килгән шигырьләрен сөйлиләр).

Әби. Балакайларым, бик матур шигырьләр өйрәнгәнсез.

Алып баручы. Хәзер малайлар мәдрәсәдәге хәлләрне тасвирлаган "Таз малай" биюен күрсәтерләр. (Бию башкарыла).

Алып баручы. Безнең халкыбыз - моңлы халык бит ул. Элек әбиләребез бик күп бәетләр, мөнәҗәтләр белгәннәр. Әбекәй, син безгә бүген берәр мөнәҗәт җырлап күрсәтмәссеңме икән?

(Әби мөнәҗәт укый: "Менә шундый заман җитәр").

Алып баручы. Зур рәхмәт сиңа, әбекәй. Әйдәгез әле, бәйрәм көн бит, биеп алабыз. (Балалар парлы бию башкаралар).

Әби. Хәзер сезгә Алсу апагыз "Сак-Сок бәете"н җырлап күрсәтер. (Бәетне тыңлыйлар). Балалар, бервакытта да каргарга ярамый. Каргаган кеше үзе гөнаһлы була. Әниләрегезнең сүзен тыңлагыз, алар сезне бервакытта да каргамасыннар, яхшылыклар гына теләсеннәр.

Алып баручы. Менә без дә бәйрәмгә дип, "Әнкәйнең догалары" исемле җыр өйрәндек. (Балалар җыры башкаралар).

Әби. Ә сез, балалар, кешенең асыл сыйфатларын беләсезме?

Балалар. Әйе, беләбез.

**1 нче бала.** Беренчесе - намус.
Кеше өчен иң әүвәл - намус, дигән.
Намусыңны сатып итмә табыш, дигән.
Байлык өчен илен, көнен саткан кеше
Ике дөнья өчен дә ул - явыз, дигән.
**2 нче бала.** Икенчесе - акыл.
Икенчесе - иң кыйммәте - акыл, дигән.
Акылсызда акыл ягы такыр, дигән.
Акылсызда намус та юк, иман да юк.
Ялганга ант итеп, барын сатар, дигән.
**3 нче бала.** Өченчесе - әдәп.
Өченчесе - иң кыйммәте - әдәп, дигән.
Әдәп көчле мәхәббәткә сәбәп, дигән.
Әдәпсездә бәхет тә юк, тәүфыйк та юк,
Кеше исемен күтәрү дә гаҗәп, дигән.
**4 нче бала.** Дүртенчесе - күңел.
Дүртенчесе - иң кыйммәтлесе - күңел, дигән.
Күңеле бозык кеше - кеше түгел, дигән.
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы,
Яшәмә дә үлеп җиргә күмел, дигән.
**5 нче бала.** Бишенчесе - сабыр.
Бишенчесе - иң кыйммәтлесе - сабыр, дигән.
Сабыр кеше зур бәхетләр табар, дигән.
Бер дә юкка ачуланып дөнья бозу
Бер кайгыдан икенчегә салыр дигән.

Алып баручы. Әйе, кеше өчен намус, акыл, әдәп, күңел, сабырлык - иң кирәкле сыйфатлар. Алар бер-берсе белән нык бәйләнгәннәр.

**1 нче бала.** Оран салмыйм, кычкырмыйм мин,
Масаймыйм синең белән.
Киләчәккә барасың син,
Туган тел, минем белән.
**2 нче бала.** Синең белән булганга мин,
Шатланып җырлыйм менә.
Җырлаган саен яңа җыр
Канат җәя күңелемдә.
**3 нче бала.**
Аннан күтәрелеп китеп,
Оча дөнья күгенә.
Туган телем, хәзер миңа
Бөтен дөнья күренә.

*"Туган тел" җыры башкарыла. (Г.Тукай сүзләре, татар халык көе).*


Алып баручы. Аллаһы Тәгалә җир йөзенә тынычлык, һәммәбезгә дә сәламәтлек, бәхет-шатлык, авыруларга шифасын бирсә иде. Әмин!

**4 нче бала.**
Барыгызга да булсын хәер-дога,
Буыннар чылбыры өзелмәсен җирдә.
Тыныч булсын еллар, яңа туар таңнар,
Изге нурлар иңсен һәр иманлы өйгә.

(Ураза бәйрәме шуның белән тәмам була).

**Дамир СИРАҖИЕВ,**
**Әтнә районы,**
**Югары Сәрдә авылы**

# Чайнворд "ТУГАН ҖИРЕМ - ТАТАРСТАН"




Нияз МИНГАЛИЕВ төзеде

1.Композитор, "Шүрәле" балеты авторы. 2.Композитор С.Сәйдәшевнең Т.Гыйззәт пьесасына язган музыкаль драмасы. 3.Чаллыда чыга торган йөк автомобиле. 4."Ак Барс" һөҗүмчесе, алкалы хоккей буенча дөнья чемпионы (2008). 5."Самат" операсы авторы. 6.Язучы Г.Бәширов романы. 7.Россия чемпионы, Казанның суда туп уйнау командасы. 8.Татарстандагы елга. 9.СССРның халык рәссамы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе. 10.Герой-шагыйрь М.Җәлил шигыре. 11.Татарстан халкының килешеп яшәве. 12.Татар халык җыры. 13.Язучы, "Итил суы ака торур" тарихи романы авторы. 14.Шагыйрь, "Курск дугасы" поэмасы авторы. 15.Тарихчы, дин галиме исемен йөртүче Казан мәчете. 16.Язучы, "Хуҗа Насретдин" комедиясе авторы. 17.Казандагы химия сәнәгате предприятиесе. 18.Халкыбызның легендар җырчысы. 19.Татарстандагы меңьеллык шәһәр. 20.Шагыйрь, Һ.Такташ поэмасы. 21.Казанның ирләр баскетбол командасы. 22.Татарстанның халык артисткасы, Г.Бәшировның "Җидегән чишмә" шигыренә көй язган композитор. 23.Татарстандагы район үзәге. 24.Татарстанның беренче Президенты. 25.Татарстанда җитештерелә торган очкыч төре. 26.Татар фольклорының афористик жанры. 27.Казандагы күл. 28.Татарстанның казылма байлыгы.

# Иске Казанда РАМАЗАН

***Мин бала чакта, рус инкыйлабына кадәр, без Казанда яшәдек. Рамазан аенда Казанда сихерле гүзәллек һәм шатлык була, ә беренче сәхәр бигрәк тә матур була иде. Әүвәлге кечне балалар йокларга иртәрәк җибәрелә иде. Тәмле сәхәр ашларының исләре аңкып тора, йокы да килми. Тәрәзәдән шәһәрне карап ята идем. Һәрбер өй яктыртылган, әйтерсең лә, күктән йолдызлар ява.***



Төн уртасында әнием мине уятырга килә, һәм без бергәләп аш бүлмәсенә төшәбез. Өстәлдә иң тәмле бәйрәм ашлары тезелгән. Бөтен өй белән, бала-чагалар да, бергәләшеп сәхәргә торабыз. Таң атар алдыннан, бабакаем сәхәрне ниятләргә Коръән укый, бөтенебез, кул күтәреп, бергә дога кылабыз. Көмеш нурлар сызылып күк яктыра, кошлар сайрый башлый... Чынлап та, Казан сихерле шәһәр икән дип, хәйран кала идем.

Иртәгесен абый-энеләрем белән бергә без соң тора идек. Көн бик тыныч була иде. Урамнарда хәрәкәт аз. Без, балалар, ураза тотмасак та, ара-тирә ачыкканчы "ураза" тота идек. Бабакай һәм әти, Коръән укып, тәсбих тартып, сәдакаларыбызны һәм зәкятебезне кемгә һәм ничек бирү турында сөйләшәләр. Әбекәй һәм әниебез Коръән укып дога кылганнан соң, безнең бәйрәм киемнәребезне һәм фәкыйрьләргә бирергә дип ашлар, сәдакалар әзерли. Балаларга мөмкин кадәр шау-шусыз уйнарга кушалар иде.

Икенде намазыннан соң көн буе тып-тын булган урамнар уяна, җанлана иде. Ифтарга кирәкле ашларны сатып алып, халык өйләренә ашыга. Өйдә ифтар ашын мөмкин кадәр тәмле әзерләргә дип, хатыннар мутфакларына җыела. Бөтен урам буенча малайлар, муеннарына тасма белән агач тартма асып кәләвә һәм пәхләвә сатып йөриләр. Берсе җырлап йөри: "Кәләвә! Кәләвә! Сатам майлы пәхләвә!" Аңа ияреп, икенче сатучы малай кычкыра: "Кәләвәнең кайнары, агып тора майлары!" Тавышлары бөтен Казан урамнарына яңгырый. Шикәр белән балны кайнатып төрле сыйфатта катырган кәләвә бик тәмле була иде. Ачы камыр, ак май һәм чикләвек белән ясаган пәхләвәне дөньядагы иң тәмле перәнник дип ярата идем. Казанда бөтен кеше, аз гына булса да, шул Рамазан татлыларын ифтар чәенә сатып ала иде.

Казанның егерме ике мәчеттәннән бик моңлы ахшам азаны яңгырый. Халык өйләренә ашыга. Су һәм бер җимеш белән авыз ачалар. Имкяны булганнар хаҗ хөрмәсе белән авыз ача.

Ахшам намазыннан соң гаиләләр җыелып ифтарга утыралар. Ифтардан соң халык тәравих намазына юнәлә иде. Урам тулы халык. Мәчет урамы буйлап фонарь яктыртып кәләвә-пәхләвә сатучылар тезелеп тора, мәчетләр тулы була иде. Без мәчеткә керә алмасак, башкалар кебек, моңлы тавышлар белән укылган Коръәнне тыңлап, бер мәчеттән икенче мәчеткә йөри идек. Тәравихтан соң дуслар бер-берсенә чәйгә барыша иде.

Бәйрәм көне - бу сихерле, матур Рамазан аеның чәчәге. Бәйрәм якынлашкан саен, һәр кич йокыга киткәнче, бәйрәмгә кадәр ничә көн калганын саный идем - җәннәттән явып төшкән йолдызлар арасында.

**Разия ДӘҮЛӘТ,**
**АКШ, Калифорния**
**(Язучы, мөгаллимә, Америкадагы Төрек-татар берләшмәсенең беренче әгъзаларыннан булган Разия ханымның бу хатирәсе берләшмәнең басмасыннан алынды).**

# КАЙСЫ МӨҺИМРӘК: диниме, әллә дөньяви белемме?

***СОРАУ. Әлхәмдүлилләһ, Исламга мин күптән түгел генә килдем һәм түбәндәге проблемага юлыктым: мәктәпне тәмамлагач, мин югары мөселман уку йортына (мәдрәсәгә) керергә теләдем, ләкин әти-әнием сораштыра торгач, мәдрәсәдә дөньяви белем бирмәүләрен, ә бары тик дини белем генә бирү хакында белделәр. Минем әти-әнием дин тотмаганлыктан, алар уйлаганча, тормышта акчаның алай ук зур әһәмияткә ия түгеллеген аңлатуы кыен. Моны аларга ничек аңлатырга?! Зинһар, ярдәм итегез!***

ҖАВАП. Дини күзлектән караганда, мөселманга торачак җирсез калам, югалам, тормышым хезмәтемнән һәм һөнәремнән генә тора дип уйлау һич кенә дә тиеш түгел. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә ризык белән тәэмин ителешнең һәм тормыш өчен кирәк әйберләрнең үз кулында булуын белгертә.

Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә: "Җирдәге һәр җан иясенең ризыгы Аллаһ кулында, дәхи аларның торачак җирләрен һәм үлгәч күмеләчәк җирләрен белер. Барчасы Ләүхул - Мәхфүздәге китапта язылмыш" ("Һүд" сүрәсе, 6 нчы аять)

Әлеге аятьтән шуны аңларга мөмкин: бер генә кеше дә, бер генә төр җан иясе дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан үзенә язылганны һәм билгеләнгәнне алып бетермичә, бу дөньядан китмәс! Әти-әниегезгә тормыштан берничә мисал китерегез. Акчаның ул кадәр үк мөһим булмавын һәм аның күләме һәрвакытта да белемнән һәм эштән генә тормавын аңлатыгыз.

Дини белем алу өчен, дини уку йортына керү бик үк мәҗбүри дә түгел. Иң мөһиме - белем алу һәм аның буенча бару, ә "катыргы" түгел. Кибет киштәләрендә дини продукция бик күп: китаплар, аудио һәм видеодисклар, газета-журналлар, Интернет-контент турында әйтеп тә торасы юк! Вариант буларак, әти-әниең белән каршылыкка килмәс өчен, дөньяви уку йортына кереп, шул ук вакытта үзеңнең ислам дине өлкәсендәге белемеңне дини әдәбият һәм аудио-видеопродукция ярдәмендә баетырга мөмкин.

Сүз дә юк, дини уку йортында белемне тирәнтен һәм тулырак итеп алырга була. Әгәр дә сез үз алдыгызга ислам динен тарату максатын һәм аны башкаларга өйрәтүне куйсагыз, бу очракта әти-әниегезне күндерергә тырышыгыз һәм ислам уку йортына керегез!

Тагын, дөньяви белем белән беррәттән дини белем бирүче югары уку йортына да керергә мөмкин. Мәсәлән, Маммадибир ар-Рочи исемендәге Теология һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты.

Психологик күзлектән караганда, Сезнең дини белем алуга омтылуыгыз мактауга лаек. Ләкин сезнең бу омтылышыгыз әти-әниегез белән каршылыкка килүгә сәбәп булырга тиеш түгел. Сезнең үҗәтләнүегез аркасында, каршылыкка килүнең сәбәбе итеп, әти-әниегездә дингә карата начар мөнәсәбәт тууы мөмкин, ә бу хәл булмаска тиеш. Сез һәрвакытта да дөньяви белем белән дини белемне берләштерә аласыз.

Кызганычка каршы, барлык кешеләр дә әлеге белемнәрнең башка нәрсәләрдән күпкә мөһим икәнен һәм аңа ничек тә булса ия булырга кирәклеген аңламыйлар. Бу – бер яктан. Ә икенчедән, сезнең тормышыгызның ничек буласы, гомумән, билгеле дә түгел. Һичшиксез, алган билгеле бер һөнәрегез сезгә киләчәктә бик ярдәм дә итәр. Сездә әлеге һөнәргә карата эчке омтылыш һәм әлеге өлкәдә аерым сәләт тә булуы зарур.

Әлеге сорауда үзегезнең карашыгызны тикшереп чыгыгыз, һәрвакытта да дөрес юлны табарга мөмкин. Иң мөһиме: үзегезне әти-әниегезгә капма-каршы куймагыз, аларның фикеренә дә колак салыгыз һәм хөрмәт итегез. Үзегезнең якка бары тик йомшак сүз һәм игелекле эш белән генә җәлеп итәргә мөмкин.

**ISLAM.RU**



## Казанда намаз вакытлары

| КӨН | ИРТӘ | КОЯШ | ЗӘВӘЛ | ИКЕНДЕ | АХШАМ | ЯСТУ | КЫБЛА | КӨН ОЗ. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 27 авг | 03:56 | 05:37 | 12:46 | 17:34 | 19:51 | 21:32 | 13:29 | 14:14 |
| 28 авг | 03:58 | 05:39 | 12:45 | 17:32 | 19:49 | 21:28 | 13:29 | 14:10 |
| 29 авг | 04:01 | 05:41 | 12:45 | 17:30 | 19:46 | 21:25 | 13:29 | 14:05 |
| 30 авг | 04:04 | 05:43 | 12:45 | 17:28 | 19:44 | 21:22 | 13:29 | 14:01 |
| 31 авг | 04:06 | 05:45 | 12:44 | 17:26 | 19:41 | 21:19 | 13:29 | 13:56 |
| 1 сен | 04:09 | 05:46 | 12:44 | 17:24 | 19:39 | 21:15 | 13:29 | 13:52 |
| 2 сен | 04:11 | 05:48 | 12:44 | 17:22 | 19:36 | 21:12 | 13:29 | 13:47 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №2 (99) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәклләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Дизайнер-верстка:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 дәнә. **Заказ:** Е-502

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 26 август, 12.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "ТатМедиа" ААҖ филиалы "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**